ГАПОУ «Арский педагогический колледж имени Габдуллы Тукая»
МУ «Управление Образования Исполнительного комитета Кукморского района РТ
Некоммерческая организация по оказанию социальных услуг семьям с детьми «Шанс»
МБДОУ «Детский сад общеразвивающего вида № 6 «Радуга» г. Кукмор»

# Колыбель - в большой мир дверь



# Бишек - зур дөньяга ишек

Сборник методических разработок межрегионального конкурса

2024

**УДК 373.1; 373.2; 377.5; 377.6; 378**
**ББК 74.1; 74.2; 74.4**

**Составитель:**
**Ямалова З.И. Директор автономной некоммерческой организации по оказанию социальных услуг семьям с детьми «Шанс»**

**Научный консультант, редактор:**
**Гарипова Г.Ф.**, **директор ГАПОУ «Арский педагогический колледж имени Г.Тукая»**

**Ответственный за выпуск:**
**Вахитова Г.Г., воспитатель по обучению татарскому языку, высшей квалификационной категории МБДОУ «Детский сад № 6 «Радуга» г.Кукмор**

**Сборник авторских методических разработок, для педагогов дошкольных образовательных учреждений межрегионального конкурса «Колыбель-в большой мир дверь», «Бишек-зур дөньяга ишек» (МБДОУ «Детский сад № 6 «Радуга» г.Кукмор) – Кукмор, 2024. – Вып. 1, часть 1. - 73 с.**

**Халиуллина Альмира Радифовна**
**МБДОУ “Шушмабашский детский сад”**
**Арский муниципальный район**

**Әлли-бәлли бәү,балам,**
**Зирәк булып үс,балам!**

(Зурлар төркемендәге балалар һәм әниләр белән берлектә уздырылган ачык шөгыль ).

**Максат**: Халкымның борынгы гасырлардан килгән,күңел түрләреннән чыккан бишек җырлары белән таныштыру.
Балада әнисенә,әбисенә карата ярату,хөрмәт итү кебек сыйфатлар тәрбияләү.
**Җиһаз**:интерактив такта,элеккеге бишек,аның түшәмгә эленү күренеше, хәзерге заманча бишек рәсеме, бишек җырлары белән аудио һәм видеоязмалар.

**Барышы**:

Тәрбияче:Хәерле көн ,кадерле әниләребез!Исәнмесез, балалар! Хәлләрегез ничек?
(торып исәнләшү,балалар бер-берсе белән сәламләшәләр)
Тәрбияче:Балалар,безнең бүгенге шөгылебез гади генә түгел.Бүген бездә кунакта иң кадерле,иң газиз кешеләребез-әниләребез. Шөгылебез дә алар белән берлектә узар. Шөгылебезне башлыйбыз.
Магнитофон тасмасында Роберт Миңнуллинның “Тал бишек “җыры куела.Музыка тына.
Ак дөньяны сиңа бүләк иттем,
Ак биләүгә сине биләдем.
Ак биләүгә сине биләдем дә,
Ак бәхетләр генә теләдем.
Бар җиһанны нурга күмеп,гаилә җепләрен тагын да ныграк бәйләп дөньяга сабый аваз сала.Берни белән дә тиңләп булмый торган Аллаһе Тәгаләнең иң олы бүләге.Әти-әнинең иң олы шатлыгы,бәхете,эби-бабайның балдан да татлы җимеше.
Ап-ак биләүгә төреп сабый баланы әнисе иң элек куенына кысып,иң-иң матур теләкләрен тели һәм бишеккә сала.
Әйдәгез,экранга күз салыйк.
(экранда борынгы эленмәле бишек,аның янында әни кеше бишекне тирбәтеп утыра).
Балалар,менә бу борынгы бишек.Ә нәрсә соң ул бишек?Әйдәгез әле,аңлатма биреп китик.
Бишек-яшь баланы тирбәтеп йоклату өчен тал агачыннан үреп,махсус җайланып эшләнгән асылмалы йоклату урыны.Ул гел өйнең түренә түшәмгә эленеп куела торган булган.
Тәрбияче:Балалар ничек уйлыйсыз,өйләрдә хәзер бишекләр бармы.
Балалар:Юк,хәзер карават яки коляска куела.
(чагыштыру өчен экранда заманча бишек рәсемнәре куела.)
Тәрбияче:Дөрес ,балалар,хәзер инде мондый бишекләрне музейларда гына күреп була.Экраннардан күренгәнчә,хәзер заманча бишекләр ,аларның да нindиләре генә юк.
Балалар,ә бишеккә салгач,сезнеңчә әйтсәк,караватка салгач,бала тиз генә йоклап китте микән?
Балалар:Юк,аңа әниләр җыр җырлыйлар.
Тәрбияче :Бик дөрес.Менә мондый җырлар “Бишек җыры “дип аталган.
Әйдәгез бишек җыры тыңлап китик.
Җилләр дә тынган инде,
Күлләрдә томан инде,
Син дә йокла, күз нурым,
Әлли-бәлли, былбылым.
Күк тулы йолдыз гына,
Ай йөри ялгыз гына,
Син дә йокла, йолдызым,
Әлли-бәлли, былбылым.
Бал - шикәрдән тәмлесең,

Күр төшеңнең тәмлесен,
Ак көмештәй ай нурым,
Әлли-бәлли, әлли-бәлли,
Әлли-бәлли, былбылым!
Алсу нурлар йөгерсен,
Җилбер-җилбер җил өрсен,
Уятырмын: «Тор, кызым!»
Әлли-бәлли, былбылым.

Ә нәрсә соң ул "Бишек җырлары".Бишек җырлары-моннан биик күп еллар элек гади халык тарафыннан барлыкка килгән.Бишектәге сабыйны тирбәтеп йоклатканда яки юатканда моңлы итеп җыр суза торган булганнар. Сабый эле аңламаса да шушы җырларны тыңлап тынычланып йоклап китә торган булган. Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү калган вакытта башкарыла. Ана ул мәлдә күңеле белән баланың эчке халәтенә якыная. Әлеге җырлар аша сабый матурлык, ананың йөрәк җылысын тоя.Ана кеше шушы җырлар аша баласына изге теләген тели,киләчәгенең якты,матур булуын тели

Әйдәгез, бүген кунакка килгән әниләребез тарафыннан Бишек җырлары тыңлап үтик.

(Бер-ике әни алдан махсус бишек җыры өйрәнеп килә).

Әлли-бәлли итәр бу
Йокыларга китәр бу,
Бәү-бәү итеп, күз йомып,
Изрәп кенә китәр бу.
Алма кебек тәгәрәп,
Үсеп буйга җитәр бу,
Абыйлары артыннан
Казаннарга китәр бу.
Казаннарда укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Тәрбияче :Афәрин,әниләр.Балалар,әниләребезне алкышлыйк әле.

Тәрбияче :Заманнар үзгәрә тора.Бишек җырларын шагыйрь-шагыйрәләребез дә иҗат итә башлый.

Нәкыйпова Адилә һәм Шакирова Ясминә сезгә Резеда Вәлиеваның "Бишек җыры"н җырлап китәрләр.

Тәрбияче:Балалар,әйдәгез,әниләр белән бергәләшеп "Иң кадерле сүзләр" әйтешү уены уйнап алабыз. (Бала әнигә,әни балага матур сүзләр әйтә).

Тәрбияче: Кадерле әниләребез,балаларыбыз шөгылебез шуның белән тәмам .
Шөгылебезне Габдулла Тукайның "Бишек җыры" белән тәмамлыйк..

Бала-бәгырь җимеше дибез. Һәр эти-әни дә үз баласының иманлы, тәүфикълы, игелекле булып үсүен тели.Ә балада шушы сыйфатларны тәрбияләү нәкь менә бишектән башлана.Шуның өчен дә эби-бабаларыбыздан мирас булып калган бишек җырларыбыз һәр өйдә җырлансын,бу җырларның учагы беркайчан сүнмәсен,дәвамлы булсын.

Әнкәемнең җырын тыңлап
Тал бишектә үскәнмен
Шул җыр белән канатланып
Тәпи атлап киткәнмен.
Бишек җыры илһам биргән
Юлдаш булган җаныма.
Әнкәемнең нурлы йөзе
Мәңгегә күз алдымда.
Бишек җыры белән иңгән
Күңелемә яктылык, —
Туган җирне һәм гомерне
Сөю хисе саф булып.

**Халиуллина Ләйлә  Исраилжан кызы**
**МБДОУ «Центр развития ребенка – детский сад №4 города Арск»**
**Арского муниципального района**

**Конспект-шөгыль «Бәби ашына әзерләнәбез»**

**Максат**: халкыбызның күркәм гадәтләре, бәби ашы, аның йолалары белән таныштыру.
**Бурычлар**:
- белем бирү бурычлары: татар халкының йолалары аша халык авыз иҗаты, матур әдәбият үрнәкләре белән танышу; бәйрәм-йолалар турында балаларның белемнәрен тулыландыру;
- үстерү бурычлары: бәйләнешле сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын, кул чуклары моторикасын үстерү;
- тэрбияви бурычлар: татар халкынын мэдэниятенэ хэм гореф-гадэтлэренэ карата кызыксыну уяту, олкэн буыннарга карата мэхэббэт, ихтирам тэрбиялэу.

**Топ белем биру олкэсе**: танып белу
**Интеграль белем биру олкэлэре**: социаль-шэхси усеш, сойлэм усеше, нэфасэти-сэнгать усеш, физик үсеш
**Методик алым:** уен, курсәтмә материал, сорау-җавап, үсендерү, мактау, сүзлек остендә эш
**Материал һәм җиһазлар**: экран, ноутбук, дидактик уен «Кем нәрсә ярата?», дидактик уен «Беләзек», презентация «Татар халык ашлары», бала елаган тавыш, презентация «Корым ничек барлыкка килә», тозлы камыр, такта, уклау, алъяпкыч, бишек, курчак, шарлар, милли орнаментлы формалар.

**Эшчәнлек барышы**

Кереш өлеш
Тәрбияче: Исәнмесез, балалар! Кәефләрегез ничек?Безнең күрше апабызның гаиләсендә бик шатлыклы вакыйга булды бит әле: аларның кечкенә бәбиләре туды. Шул уңайдан «Бәби ашы» на әзерләнеп йориләр. Кибеткә чыгып киткән арада бәбине миңа карап торырга кушканнар иде. Сез дә миңа ярдәм итә алмассыз микән? Үзем дә бераз борчылып торам. Миңа булышасызмы, балалар?
Балалар: Булышабыз!
Тэрбияче: Балалар, ә сезнең энеләрегез, сеңелләрегез бармы? Сез аларга ничек булышасыз? (Балалар җавабы)
Төп өлеш
Тәрбияче : Әйдәгез эле, бәби белән бергәләп танышыйк әле (бергәләп бишек янына киләләр)
-Ишетәсезме, нинди моңлы җыр ишетелә. Сезнең мондый җыр ишеткәнегез бармы?
-Балалар, бу бишек җыры. Бишек жырлары, баланы бишектә тирбәтеп йоклатканда көйләнә. Бишек тирбәткәндә килеп чыккан әлеге җырларны бишек җырлары дип йөртә башлаганнар.
Бишек электән ук табигый материаллардан хәзерләнгән. Кайбер якларда  тал чыбыктан үрелгәннәре да очрый, тар гына такта кисәкләрен бизәкләп  ясаганнарын да очратырга мөмкин. Бишекне дүрт тактадан рамка кебек озынча итеп эшлиләр . Аның төбенә нык тукыма тегеп куялар. Бишек сиртмә ярдәмендә ыргакка эләгә һәм түшәмгә ныклы итеп беркетелә (бишек күрсәтелә).
Балалар, сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы? Чыбылдык ул – бишек өстенә каплап куела торган  тукыма. Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Бәби рәхәтләнеп йоклый. (чыбылдык күрсәтелә)
Ана   бишек җыры җырлагандасабыена үзенең изге теләкләрен тели.  Бишек җырлары тыңлаган сабый тыныч холыклы булып үсә. Бала елаганда да, ана сабыйны бишек җыры

көйләп юата. Ул сөйләшә белмәсә дә, сүзләрне аңламаса да бала җырны тыңлап изрәп йокыга киткән.
(Бала елаган тавыш ишетелә)
Тәрбияче Әй, жаным, уяттык та инде бәбине. И, бигрәк кечкенә инде. Сез дә шулай нәни генә булдыгыз микән? Йокыдан уяткан энилэребез
Йокыдан уяту
Кызым,  тор әле, тор,
Ач күзеңне: дөньядыр,
Озак йоклама син тор,
Озак йоклаганның бәхете юктыр.
Тәрбияче: Кара әле синең яныңа күпме апалар, абыйлар килгәннәр.
Балалар, э сезне әниләрегез иртән ничек йокыдан уята?
- Кызым, йокыдан уян.
- Улым алтыным, тор инде.
- Кызым, кояшым, уян. Бакчага соңга каласың
Тәрбияче: Әйдәгез әле, улларым, кызларым, баланы уяту сүзләрен бергәләп кабатлап алыйк.
Кызым, тор әле, тор,
Ач күзеңне: дөньядыр,
Озак йоклама син тор,
Озак йоклаганның бәхете юктыр.
Тәрбияче: Ә бәхет теләү нәрсә соң ул, балалар? Беләсезме?
Бала: Әйе, бәхет ул – акыллы, белемле булу; сау-сәламәт булып, әти – әни белән бергә гөрләшеп яшәү.
Тәрбияче: Сез мине шаккатырасыз, күп нәрсәләр беләсез.
Балалар, бәбине тотып карыйсыгыз килэме? Әйдәгез әле, әкрен
генә мендәрчекләргә утырыйк. Бәбине бер-беребезгә биргәндэ әкрен генә, сак кына бирик, ярыймы балалар
( балалар сак кына бәбине бер-берсенә бирәләр)
Уен «Матур сүз»
(Һәр бала бәбине кулына алгач бәбине яратып аңа 1 матур сүз әйтә)
- Син минем нәнием, йомшагым, кояшым, тәтием, алтыным, сабыем х.б.(тулы жомлэ белән җавап бирәбез)
Тәрбияче: Афәрин, балалар, менә сез нинди матур сүзләр беләсез икән. Э хәзер әйдәгез әле бәбине йоклатып алыйк. Балалар, әниләрегез сезне нинди бишек жырлары жырлап йоклата? Баланы ничек юатабыз? Э мин менэ мондый бишек җыры беләм.
Бишек жыры жырлап йоклату
Әлли-бәлли итәр бу,
Усеп буйга җитәр бу.
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып китәр бу (бәби йоклап китә)
Тәрбияче: Балалар, элек бәбиләргә күз тимәсен өчен маңгайларына корым сөртэ торган булганнар (презентация: корым, күмер сузләренә аңлатма биреп кителә, элек мичкә утын якканнар, утын янып беткәч аның корымы кала). Ә без аңа күз тимәсен өчен бергәләп беләзек ясап бүләк итик. (Балалар һәрберсе берәр сәйлән алып җепкә кигезә һәм балага теләк тели)
Беләзек ясау
(Мендәрчекләргә утыру)
Тәрбияче: Балалар, татар халкы элек-электән яңа туган сабыйга исем кушуга зур җаваплылык белән караган. Исеме җисеменә туры килә торган матур эчтәлекле, аһәңле, җиңел һәм анык әйтелешле исемнәр бирергә тырышкан. Һәр исем билгеле бер

мәгънәгә ия.  Ә безнең бәбиебезнең исеме ничек? (Айсылу). Айсылу исеме нәрсәне аңлата? (ай кебек сылу, чибәр)
Тәрбияче: Балалар, сезнең исемнәрегез нинди мәгънәне аңлата? Минем исемем Раилә нигез салучы дигән мәгънәгә ия. Э сезгә нинди татар исемнәре ошый? Дәү әни, дәү әтиләрегезнең исемнәре ничек? (Балалар җавабы)
Тәрбияче: Без әби-бабаларыбызның бик кунакчыл булуын, кунак киләсе булса, мул итеп ризык пешерүләрен дә беләбез. Килгән кунакны кыстый-кыстый сыйлыйбыз. Әйтегез әле, балалар, безнең татар халкы кунакны нинди ризыклар белән сыйлый? (балалар җавабы)
(Слайдлар татар ризыклары белэн)
«Дөресен әйт!» уены.
Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар
Бәрәңге, ит, тоз салып
Почмаклар ясаганнар. (Өчпочмак)
Вак-вак кына итеп кисеп,
Өяләр аны таудай
Чак-чак кына алып, өзеп,
Аша дустым, син шулай. (Чәкчәк)
Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың,
Ул нәрсә? (Коймак)
Дидактик уен «Кем нинди ризык ярата?»
Балалар өстәлдән татар халык ризыклары ясалган рәсемнәр алып мольбертка ябыштыра:
- Мин өчпочмак яратам
- Мин бәлеш яратам
- Мин чәк-чәк яратам
- Мин кыстыбый яратам х.б.
Тәрбияче: Балалар, без бүген «Бәби ашы»на киләсе кунакларга баллы чәй ризыгы (печенье) ясарбыз.
Балалар өстәл янына киләләр, алъяпкыч, баш киемнәрен кияләр, бер-берсенә алъяпкычларны бәйләргә булышалар. Тәрбияче эш тәртибен аңлата (уклау белән камырдан түгәрәк жәем жәябез х.б.)
Тәрбияче: Кунак килү турында төрле юраулар бар бит, сез беләсезме?
- Песи битен юса, кунак килә
- Чыпчык тәрәзәдән килеп чукыса, кунак көт.
- Саескан йорт-җир тирәсенә килсә, кунак чакыра.
Тәрбияче : Табын янында әдәп кагыдәләрен белүебезне әйтеп үтик әле. (балалар җавабы)
- Авызда ризык булганда сөйләшергә ярамый
- Терсәкләрне өстәл өстенә куймыйлар
- Аякларны селкеп утырырга ярамый
- Ашаганда, кашыкны тәлинкәгә бәреп , тавыш чыгарып утырырга ярамый
Тэрбияче: Бик дорес, балалар. Табын артында утыру кагыйдәләрен дә онытмаска кирәк. Балалар,э сезгә кунаклар киләме? Сез кунакка барырга яратасызмы? Ә ни өчен без кунак килгәнне яратабыз?
Бала. Чөнки кунаклар килгәч күңелле, уйныйбыз, җырлыйбыз, тәмле сыйлар белән сыйланабыз.
Тәрбияче. Балалар, әйтегез әле, кешеләр ни өчен бер-берсенә кунакка йөриләр?
- Бергәләшеп бәйрәмнәр уздыруы күңеллерәк.
- Чөнки кунакта тәмле ризыклар белән сыйлыйлар.
- Туганнар һәм дуслар белән аралашып яшәргә кирәк.
Йомгаклау

Эшне тогэллэу, балаларны мактау, ясаган ризыкларны күрсәту.
Тәрбияче: Улларым, кызларым, сез бигрәк уңганнар да инде. Без бүген сезнең белән нәрсәләр эшләдек әле? Ошадымы сезгә?
Миңа да сезнең белән бик ошады. Сез мина бик ярдәм иттегез. Минем дә сезне шатландырасым килде.
Капчыктан ак шарлар чыга.
Тэрбияче: Кечкенә Эминэбезгэ шушы ак шарлар кебек ак бәхетләр телик, балалар!

**Мухаметзянова Гелюся Ахияровна**
**МБДОУ «Детский сад №5 «Созвездие» г. Кукмор»**
**Кукморского муниципального района РТ**

## "Йокы кунакка килде"

**Максат:** Әңгәмә, җырлау аша бишек җыры жанры турында күзаллау формалаштыру.
**Бурычлар:**
- балаларны төрле бишек җырлары белән таныштыру;
- тыңланган музыка турында сөйләү осталыгын формалаштыру;
- балаларда халык җыр иҗатына кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү, җиңел, тигез тавыш белән җырлау осталыгын формалаштыру, җырларның көйен дөрес интонацияләү.

**Җиһазлау:** колонка, ноутбук, бишек, курчак.

**Барышы:**

Г. Тукай сүз., татар халык көе "Әллүки"
*Балалар төркемгә керәләр һәм бишек тирәсендәге урындыкларга утыралар. Тәрбияче (бишекне селкетеп).*
Безнең Кәрим бик арган,
Ул көн буе уйнаган.
- Ә Кәрим йокласын өчен аңа җыр җырларга кирәк.
- Балалар, ә бала йокыга талсын өчен нинди җыр җырларга кирәк?
- Әлбәттә, бишек җыры.
Әлли-бәлли, йом син күзең,
Әлли-бәлли – татлы сүзем.
Йоклый инде бөтен бәбиләр дә,
Йоклый инде хәтта әбиләр дә.
Әлли-бәлли, йом син күзең,
Әлли-бәлли – татлы сүзем.
- Бик күптәннән... Күз алдына китерү дә кыен, әниләр балаларын йокларга ятканда аларга бишек җыры җырлаганнар. Бу бишек җырлары гади түгел, ә тылсымлы булган, алар баланы йоклатканнар. Әниләр бишек җырына сүзләрне, төймәләрне җепкә тезгән күк, бер-бер артлы тезеп, кызыклы вакыйгалар уйлап чыгарганнар.Чөнки бала йоклаганчы җырларга кирәк була. Ә ул төймәләр искиткеч кызыклы, берсенә берсе һич охшамаганнар.
- Ничек уйлыйсыз, ни өчен әниләр бишек җырлары җырлаганнар? (бала йокласын өчен)
- Дөрес, бишек җырлары әниләргә баланы йоклатырга, шулай ук нарасыйга тылсымлы төш күрү өчен дә башкарылган.
*Балаларның бишек җырын индивидуаль башкаруы*.
Кыйгач кашым,
Асыл ташым!
Йоклаек икәү.
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү, бәү!
- Балалар, ә сезгә Зиләнең җырлавы ошадымы? (Әйе).
- Ни өчен? Зилә бишек җырын башкарганда сез нинди хисләр кичердегез?

- Җырда нинди назлы сүзләр җырлана? (асыл ташым, иркә, бәбкә).
- Ни өчен җырдагы сүзләр шундый назлы?
- Әйе, чөнки бишек җырлары аша әни баласына булган бөтен назын, яратуын күрсәтә. Ә хәзер мин сезгә тагын бер матур бишек җыры башкарам.
*Ак дөньямны сиңа бүләк иттем,*
*Ак биләүгә сине biләдем.*
*Ак биләүгә сине биләдем дә*
*Ак бәхетләр генә теләдем.*
Бу җырны сезнең белән бергә башкарасым килә.Әйтегез әле без аны ничек башкарачакбыз? Нинди темп белән? (акрын)
Дөрес, салмак, акрын тавыш белән.
*Балалар белән бишек җырын башкару.*
Бик яхшы, рәхмәт. Минемчә, мондый башкарудан соң балаларга иң матур төшләр генә керәчәк.
Балалар, әйдәгез әле хәзер бишекне карап китик. Карагыз әле ул нинди матур.
Алтын бишек,
Яхшы бишек.
Йоп-йомшактыр мендәре.
Мондый ямьле бишекне
Син дә килеп күр әле.
Ни өчен шигырьдә мондый матур сүзләр очрый? ( чөнки бала турында кайгырталар).
Әйе, әлбәттә, бу сүзләр аркылы ананың балага карата булган бар назы сизелә.
Ә бу матур җырларны кем иҗат иткән соң?
Халык иҗат иткән. Әни кызына җырлаган, аннан ишетеп башкалар отып алган. Шулай итеп безнең көннәргә кадәр бишек җырлары сакланган.
Без бүген нәрсә белән таныштык?
Бишек җырларын кем уйлап чыгарган? Ни өчен?
*Бишек җыры тыңлау.*
Туфан Миңнуллин шигыре, Рәшит Абдуллин көе “Куанычларым, шатлыгым булып...”

**Гарифуллина Рәмзия Хәйдәр кызы**
**татар теле тәрбиячесе**
**Борһанова Гөлнара Ринат кызы**
**укытучы- логопед**
**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы**
**"Арча 10 нчы балалар бакчасы"**
**муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе**

## “ Дәү әниемнең бишек җырлары”

Зурлар төркемендә сөйләм үстерү эшчәнлеге

**Максат:** Балаларның татар халык авыз иҗаты төре - бишек җырлары турындагы белемнәрен киңәйтү.

**Бурычлар:**
- Сөйләм телен һәм ишетеп күзаллауны үстерү аша балаларда татар халкының бишек җырлары,көнкүреш предметы булып саналган бишек турындагы белемнәрен камилләштерү.
- Халык иҗаты- җырларга кызыксыну, мәхәббәт уяту, сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
- Гаилә кыймметләренә һәм татар халкының гореф- гадәтләренә хөрмәт хисе, аларны саклау теләге уяту.

Җиһазлау һәм материаллар: бишек, видео, презентация, курчаклар, биләүләр, мендәрләр, уен өчен җырлар.

Таратма материаллар: балалар санынча кояш рәсемнәре, кызыл һәм зәңгәр түгәрәкләр
Үткәрү урыны: төркемдә

**Эшчәнлек барышы**

**1. Оештыру.**

*Тәрбияче:(*тәрбияче балаларны үз янына түгәрәккә җыя*)* Исәнмесез, балалар! Кәефләрегез ничек? Әйдәгез әле, түгәрәк ясап басыйк.
Кулларга без кагылдык
Бер – беребезгә елмайдык.
Ә хәзер урындыкларга утырыгыз.

**2. Төп өлеш.**

Бүген мин сезне виртуаль экскурсиягә чакырам. Без сезнең белән элеккеге татар өенә барырбыз. Музейга куар код ярдәмендә эләгербез *(*видео куела).

Видео эчтәлеге: Исәнмесез, кадерле балалар. Без сезнең белән татар гаиләсе йортында.Татар өенә кергәндә, сезне олы ак мич каршы ала. Бабай, утын алып кереп, мичкә яккан, ә әби бу мичтә тәмле ризыклар пешергән. Мич янына караватурнаштырганнар. Әбиләр, әниләр, кич утырып, мендәр тышлары, карават япмалары чиккәннәр. Ә менә бу талчыбыктан ясалган бишектә әни кеше, җырлап, үзенең баласын йоклаткан. Бишектә йоклаган сабый тыныч холыклы булып үскән. Әниләр генә түгел, әбиләр, дәү әниләр дә бишек тирбәткән. Монысы - сандык. Анда милли киемнәрне, чигелгән сөлгеләргне саклаганннар. Бу өстәл артында гаилә табынга җыелган. Өстәлгә бәлеш, өчпочмак, чәк-чәк, коймак куелган. Бүгенгә менә шулар. Саубулыгыз, балалар.

**Балалар белән әңгәмә.**

- Балалар, сезгә виртуаль экскурсия ошадымы?
- Нинди предметлар исегездә калды?*(Мич, сандык, карават, бишек һ.б.)*
- Балалар, нәрсә икән соң улбишек? *(Яңа туган балаларның караваты)*
- Бишекне нәрсәдән ясаганнар? *(Талчыбыктан үргәннәр)*
- Балалар, ә бишек нигә кирәк булган? *(Анда балаларны йоклатканнар)*
- Ә бала йоклату эшен кем башкарган? *(Әни, әби, дәү әни)*
- Алар баланы ничек йоклатканнар? *(Тирбәтеп һәм бишек җыры җырлар)*
- Ә ни өчен җырлаганнар? *(Бала тизрәк йокыга китсен өчен)*
- Бишек җыры ничек җырлана? (*Салмак, акрын, тыныч)*

*Тәрбияче.* Хәзер мин сезне басып ял итәргә, “Күрсәт әле, үскәнем” уены уйнарга чакырам.
Физкультминутка. Балалар, музыка астында хәрәкәтләр ясап, җырлыйлар.
Күрсәт әле үскәнем, ничек елый бәбиләр?
Менә шулай, менә шулай, шулай елый бәбиләр*(куллары белән күзләрен уалар)*
Күрсәт әле, үскәнем, ничек йоклый бәбиләр?
Менә шулай, менә шулай, шулай йоклый бәбиләр*(кулларын яңакларына куялар, күзләрен йомалар)*
Күрсәт әле үскәнем, ничек уйный бәбиләр?
Менә шулай, менә шулай, шулай уйный бәбиләр *(бер-берсе белән кул чәбәкләшәләр)*

*Тәрбияче.* Бишеккә ятучы баланың баш астына йомшак мендәр куйганнар, сабыйга җылы юрган япканнар. Ә чит кешеләр бәбигә күз тиермәсеннәр, чебен- черкиләр тешләмәсен өчен бишекне япма- чыбылдык белән каплаганнар. Күрәсезме, безнең төркемебездә дә бүген бишек бар. Бу сезнең әниләрегез - әтиләрегез йоклаган бишек. *( Тәрбияче тәрәзәдән карый).* Әнә безгә таба дәү әни килә, кулында оныгы да бар. Әйдәгез, аны каршылыйк. Тик тавышланырга ярамый икәнлеген онытмыйк, юкса, кечкенә бәбине куркытырбыз.

*Дәү әни (2 нче тәрбияче)* керә. Кулында биләүгә төрелгән бала.

*Дәү әни.* Исәнмесез, балалар. Ниһаять, сезнең янга килеп җиттем. Кызым, күз нурым да йоклап китте.

*Балалар.* Исәнмесез, дәү әни , утырыгыз. Без тавышланмабыз.

*Тәрбияче.* Дәү әни, без бәбигә дип бишек әзерләдек. Әйдә аны шунда салыйк. Дәү әни, синең оныгың кем исемле?

*Дәү әни.* Исеме -Гөлбикә. Гөлләр кебек матур кыз булсын дип шундый исем куштык.
*Тәрбияче.* Дәү әни, ә син Гөлбикәгә нинди матур сүзләр белән эндәшәсең?
*Дәү әни.* Иииии дөньядагы иң матур, җылы сүзләрне генә әйтәм. Багалмам дим, бәбкәем дим, кара кашым -карлыгачым дим.
*Тәрбияче*. Балалар, әйдәгез, без дә "Ягымлы сүзләр" уены уйнап алыйк әле. Гөлбикәгә матур сүзләр әйтик. Дәү әни тыңлап торсын.
*Балалар.*- Балам,кызым, акыллым, алмам, җимешем, хөрмәм, алтыным, йомшагым, былбылым, сабыем, кадерлем, җиләгем һ.б.
*Тәрбияче.* Балалар, ә хәзер мин сезне бирегә чакырам. Күрәсезме, идәнгә мендәрләр тезелгән. Сез үзегезгә бер мендәр сайлап алыгыз һәм аңа тезләнеп утырыгыз. Без сезнең белән "Бишек җырын таны" уены уйныйбыз. Сезнең каршыгызда икешәр рәсем. Беренче рәсемдә кояш нишли?
*Балалар.* Кояш йоклый.
*Тәрбияче.* Ә икенче рәсемнәрегездә кояш нишли?
*Балалар*. Кояш уяна.
*Тәрбияче.* Хәзер без сезнең белән төрле көйләр тыңларбыз. Әгәр сез җырны бишек җыры дип уйласагыз, кояшның йоклаган рәсемен күтәрерсез. Әгәр инде җыр кызуырак темпта икән, кояшның уянган, елмайган рәсемен күтәрегез.*(Балаларга ике бишек, ике шаян җыр тыңлатыла, балалар кагыйдә буенча рәсемнәрне күтәрәләр)*
*Дәү әни*. Балалар, Гөлбикә йоклаган арада, мин сезне бишек белән таныштырыйм әле. Бишекне сиртмәгә элеп, түшәмгә беркеткәннәр. Әниләр бишеккә япманы үзләре чиккәннәр. Яңа туган балага күлмәк- ыштаннар киертмәгәннәр, аны ак биләүгә төргәннәр. Әйдәгез, бүген мин сезне курчакларны биләүгә төрергә өйрәтәм. Сез бит булачак әниләр-этиләр. *( Дәү әни һәм тәрбияче алдан әзерләнгән курчакларны биләүгә төрергә өйрәтәләр)*
*Тәрбияче.* Дәү әни, балалар, безнең биләүдәге сабыйларыбыз ай- һай матур булдылар. Инде аларны йоклатасы гына калды. Бишек җырлары балаларны тәртипле булырга өйрәтә.
*Бишектәге Гөлбикә елап уяна.*
*Дәү әни.* Ай, Гөлбикә йолдызым да уянды, кая әле бишек тирбәтеп, җырлап йоклатыйм әле аны. Сез дә балалар урындыкларыгызга утырыгыз һәм минем белән бергә җырлап, курчакларыгызны йоклатыгыз *(Дәү әни бишек җыры җырлый, балалар алларында курчакларны тирбәтәләр).*
*Тәрбияче.* Балалар, барыбызның да бәбиләре йоклады. Әйдәгез, аларны караватларга салыйк *(Ахырдан тәрбияче һәм дәү әни балаларны үз янына җыя).*

**3. Йомгаклау.**

*Тәрбияче.* Балалар, безгә бүген кунакка кем килде? Дәү әни безне нишләргә өйрәтте?
*Дәү әни.* Күз нурларым, сез дә үсәрсез, әниләр - этиләр булырсыз, балалар үстерерсез. Шул чакта сезгә бишек җырлары кирәк булыр. Ә хәзергә аларны онытмас өчен, курчакларыгызны, өйләрегездә эне - сеңелләрегезне гел көйләп, тибрәтеп йоклатыгыз. Без Гөлбикә белән кайтыйк инде. Аның тамагы да ачкандыр, уяныр.
*Балалар.* Саубул, Дәү әни. Рәхмәт, Дәү әни.
*Тәрбияче.* Балалар, сезгә бүгенге эшчәнлек ошадымы? Кемгә ошады сез магнит тактага кызыл түгәрәкләрне беркетегез. Кемгә эшчәнлек ошамады, алар зәңгәр түгәрәкне беркетсеннәр.
*(Балалар түгәрәкләрне мөстәкыйль сайлап, ябыштыралар.)* Ә мин сезгә афәрин дим. Үскәч, сез бик әйбәт эти- әниләр булачаксыз.

**Валиуллина Юлия Николаевна,**
**Шакирзянова Рузиля Расилевна**
**МБДОУ «Арский детский сад № 2»**
**Арского муниципального района РТ**

**Тема: “Халкым җәүһәре – бишек җырлары”**
(Уртанчылар төркемендә эшчәнлек конспекты)

**Максат:** балаларның бишек җырлары буенча белемнәрен киңәйтү
**Үстерү бурычлары:** сүзлек байлыгын арттыру, хәтерен, игътибарын, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
**Тәрбия бирү бурычлары:** татар халкының гореф-гадәтләренә ихтирам, горурлану һәм хөрмәт итү хисен тәрбияләү.
**Белем бирү бурычлары:** балаларны бишек җырлары белән таныштыруны дәвам итү
**Методик алымнар һәм чаралар:** сорауларга җавап, уен, сүзлек өстендә эш, аралашу, мактау
**Җиһазлау һәм материаллар:** курчаклар, бишек, чыбылдык, биләүләр.
**Сүзлек өстендә эш:** бишек, чыбылдык, биләү
**Балалар белән әзерлек эшләре:** бишек җырлары турында сөйләшү һәм аралашу, бишек җырлары өйрәнү, курчакларны биләүгә төрү, йоклату.
**Көтелгән нәтиҗә:** бишек җырларын таный һәм җырлый белә, бишек, чыбылдык сүзләрен аңлый һәм сөйләмендә куллана ала.

**Эшчәнлек төзелеше:**
1.Исәнләшү.
2.”Бишек җыры” тыңлау
3. Бишек белән таныштыру
4. Чыбылдык белән таныштыру
5. Физкульт минут
6. “ Ягымлы сүзләр” уены
7. Курчакларны биләү
8. Курчакларны йоклату
9.”Әни кирәк” җырын башкару
10.Йомгаклау

**Эшчәнлек барышы**

-Хәерле көн, балалар! Кәефләрегез ничек?
- Без үзебезнең яхшы кәефне, матур елмаюыбызны башкаларга да бүләк итик әле.
- (бергә)
Кулларымны сузам сиңа,
Дустым елмаеп-көлеп.
Кушылсыннар башкалар да,
Безнең дуслыкны күреп.
*Талгын гына “Бишек җыры ишетелә.*
*Әлли-бәлли итәр бу,*
*Йокыларга китәр бу.*
*Йокыларга киткәчтен,*
*Бик дәү булып үсәр бу.*
-Ишетәсезме, нинди моңлы матур җыр ишетелә. Сезнең мондый җыр ишеткәнегез бармы?
-Балалар, әйе - бу бишек җыры. Бишек җыры...Никадәр йөрәк түреннән чыккан ягымлы сүзләр, иксез-чиксез матур хыяллар берни белән дә чагыштырып булмаслык ана мәхәббәте күңелләрнең иң нечкә кылларын тибрәндерерлек моң булып агыла да агыла... Бишек җырлары баланы бишектә тирбәтеп йоклатканда җырланыла. Әби-бабаларыбыз

элек-электән әйтеп килгәннәр, бишек җыры тыңлап үскән баланың теле иртә ачыла, сәләтле, акыллы бала булып үсә. Бишек тирбәткәндә килеп чыккан әлеге җырларны бишек җырлары дип йөртәләр.

Бишек электән үк табигый материаллардан ясалган. Бишекне miləш агачыннан ясарга тырышканнар, чөнки ул сыгылмалы агач, сынмаган. Әле аның шундый ырымы да булган: бишекне җимешләре күп булган агачтан ясарга кушканнар.Ягы-ягы тал чыбыктан үрелгәннәре дә, такта белән бизәкләп эшләнелгәннәрен дә очратырга мөмкин. Бишекне дүрт тактадан озынча итеп эшлиләр. Аның төбенә нык тукыма тегеп куялар. Бишек ыргакка эләгә һәм түшәмгә беркетелә *(бишек күрсәтелә).*

Балалар, сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы? Чыбылдык ул – бишек өстенә каплап куела торган тукыма. Бишекне чыбылдык белән ябып куела. Бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Бәби рәхәтләнеп йоклый. *(чыбылдык күрсәтелә)*

Ана бишек җыры җырлаганда сабыена үзенең изге теләкләрен тели. Бишек җырлары тыңлаган бала тыныч булып үсә. Бала елаганда ана сабыйны бишек җыры җырлап юата. Ул сөйләшә белмәсә дә, сүзләрне аңламаса да бала җырны тыңлап йокыга китә.

-Балалар, сезгә әниләрегез бишек җыры җырлыйлармы? *( балалар җырлап күрсәтәләр)*

*Әлли-бәлли бәү итә,*
*Кызым йокыга китә.*
*Кызым йокыга киткәч,*
*Әнисе кайтып җитә.*

- Балалар, ишеттегезме, бишек җырында әнисе сабыена нинди матур сүзләр белән эндәшә?

-Дөрес, бишек җырларында нинди генә йомшак, матур сүзләр юк! Бу җырларда әниләребезнең йөрәк җылылыгын, иркәләвен, сөюен тоясың.

- Балалар, әйдәгез бераз ял итеп алыйк.

*Физкульт минут*

Менә минем уң кулым *(Уң кулларын күрсәтәләр),*
Менә минем сул кулым *(Сул кулларын күрсәтәләр),*
Менә идән, менә түшәм *(Өскә-аска карыйлар),*
Менә шулай зур үсәм *(Аяк очларына күтәреләләр).*

- Ә сезгә әниләрегез нинди ягымлы сүзләр әйтә соң? Әйдәгез, без моны белү өчен “Ягымлы сүзләр”уенын уйнап алабыз. Бишек җыры башлануга бер-беребезгә курчакны тапшырабыз. Көй туктагач, кемдә курчак кала, шул ягымлы сүз әйтә.

-Балалар, сезнең курчакларыгыз да бик арыганнар түгелме соң, аларны йоклатырга кирәк. Элек заманда бала тугач та, аны ак биләүгә биләгәннәр . Без дә сезнең белән курчакларыбызны бәби итеп төрергә өйрәндек. Әйдәгез, кем үзенең курчагын матур итеп төрер икән?

-Ә хәзер курчакларыбызны тибрәтеп бишек җыры көйли-көйли йоклатыйк.

*Әлли-бәлли итәрсең,*
*Тыныч йоклап китәрсең.*
*Шулай тыныч йокласаң,*
*Бик тиз үсеп җитәрсең.*

-Балалар, безнең курчакларыбыз йокыга да киттеләр. Алар тынычлап йокласыннар.

- Бала - ул алтын җимеш,
Бала-ул йөрәк парәсе.

Һәрбер әти -әни үз баласын шулай кадерләп кенә үстерә, кеше итәргә тырыша. Бөтен тормышын баласына багышлый. Әйдәгез, шөгылебез ахырында әниләребезгә кояштай озын гомер телик, аларны кадерләп саклыйк, рәнҗетмик. Әниләребез турында белгән бик матур җырыбызны башкарып шөгылебезне тәмамлыйк.

**“Әни кирәк” җыры**

*1.Көннәр якты булсын өчен,*

*Йокы татлы булсын өчен*
*Әни кирәк,*
*Әни кирәк!!!*
*2.Җил-яңгырдан саклар өчен,*
*Усаллардан яклар өчен*
*Әни кирәк,*
*Әни кирәк!!!*
-Балалар сез бүген нинди яңалыклар белдегез?
-Әти-әниегезгә, дусларыгызга нәрсәләр сөйләрсез?
-Шөгелебез сезгә ошадымы?
-Сау булыгыз! сиртмәгә элеп, түшәмгә беркеткәннәр. Әниләр бишеккә япманы үзләре чиккәннәр. Яңа туган балага күлмәк- ыштаннар киертмәгәннәр, аны ак биләүгә төргәннәр. Әйдәгез, бүген мин сезне курчакларны биләүгә төрергә өйрәтәм. Сез бит булачак әниләр- этиләр. *( Дәү әни һәм тәрбияче алдан әзерләнгән курчакларны биләүгә төрергә өйрәтәләр)*
*Тәрбияче.* Дәү әни, балалар, безнең биләүдәге сабыйларыбыз ай- һай матур булдылар. Инде аларны йоклатасы гына калды. Бишек җырлары балаларны тәртипле булырга өйрәтә.
*Бишектәге Гөлбикә елап уяна.*
*Дәү әни.* Ай, Гөлбикә йолдызым да уянды, кая әле бишек тирбәтеп, җырлап йоклатыйм әле аны. Сез дә балалар урындыкларыгызга утырыгыз һәм минем белән бергә җырлап, курчакларыгызны йоклатыгыз *(Дәү әни бишек җыры җырлый, балалар алларында курчакларны тирбәтәләр).*
*Тәрбияче.* Балалар, барыбызның да бәбиләре йоклады. Әйдәгез, аларны караватларга салыйк *(Ахырдан тәрбияче һәм дәү әни балаларны үз янына җыя).*
**3. Йомгаклау.**
*Тәрбияче.* Балалар, безгә бүген кунакка кем килде? Дәү әни безне нишләргә өйрәтте?
*Дәү әни.* Күз нурларым, сез дә үсәрсез, әниләр - этиләр булырсыз, балалар үстерерсез. Шул чакта сезгә бишек җырлары кирәк булыр. Ә хәзергә аларны онытмас өчен, курчакларыгызны, өйләрегездә эне - сеңелләрегезне гел көйләп, тибрәтеп йоклатыгыз. Без Гөлбикә белән кайтыйк инде. Аның тамагы да ачкандыр, уяныр.
*Балалар.* Саубул, Дәү әни. Рәхмәт, Дәү әни.
*Тәрбияче.* Балалар, сезгә бүгенге эшчәнлек ошадымы? Кемгә ошады сез магнит тактага кызыл түгәрәкләрне беркетегез. Кемгә эшчәнлек ошамады, алар зәңгәр түгәрәкне беркетсеннәр.
*(Балалар түгәрәкләрне мөстәкыйль сайлап, ябыштыралар.)* Ә мин сезгә афәрин дим. Үскәч, сез бик әйбәт эти- әниләр булачаксыз.

**Шарафиева Дамира Габдулловна- воспитатель**
**МБДОУ “Детский сад с.Туембаш”**
**Кукморского муниципального района РТ**

**Тема: “Бишек – зур дөньяга ишек”**

**Төр:** белем бирү эшчәнлеге
**Төп белем бирү өлкәсе.** Танып белү эшчәнлеге.
**Интеграль белем бирү өлкәләре**: сөйләм үсеше,сәнгати-эстетик үсеш, физик үсеш, социаль-коммуникатив үсеш.
**Үткәрү формасы**: төркем.
**Максат:** балаларның бишек җырлары буенча белемнәрен киңәйтү
**Үстерү бурычлары:** сүзлек байлыгын арттыру, хәтерен, игътибарын, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
**Тәрбия бирү бурычлары:** татар халкының гореф-гадәтләренә ихтирам тәрбияләү.
**Белем бирү бурычлары:** балаларны бишек җырлары белән таныштыруны дәвам итү

**Төп белем бирү өлкәсе:** танып-белү, мактау
**Интеграль белем бирү өлкәләре**: сөйләм үсеше, нәфис-нәфасәти үсеш, социаль – аралашу үсеше, физик үсеш, танып-белү үсеше
**Методик алымнар һәм чаралар:** сорауларга җавап, уен, сүзлек өстендә эш, аралашу,
**Җиһазлау һәм материаллар:** өй күренеше, сәке, курчаклар, бишек, чигүле сөлгеләр, мендәр һәм урын җир,чыбылдык, биләүләр.
**Сүзлек өстендә эш:** сәке, бишек, чыбылдык, биләү
**Балалар белән әзерлек эшләре**: бишек җырлары турында сөйләшү, бишек җырлары өйрәнү, курчакларны биләүгә төрү, йоклату.
**Көтелгән нәтиҗә**: бишек җырларын таный һәм җырлый белә, бишек, чыбылдык сүзләрен аңлый һәм сөйләмендә куллана.

**Эшчәнлек төзелеше:**
1.”Бишек җыры” тыңлау
2. Бишек белән таныштыру
3. Чыбылдык белән таныштыру
4. Курчакка исем кушу
5. “ Ягымлы сүзләр” уены
6. Курчакларны биләү
7. Курчакларны йоклату

**Эшчәнлек барышы.**

Зал матур итеп милли бизәкләр белән бизәлгән. Түрдә борынгыча бизәлгән йортның эчке күренеше: диварларда борынгы милли сөлгеләр, өй кашагалары, чигүләр эленгән, түшәмгә ыргак ярдәмендә беркетелгән бишек.
Тәрбияче. Менә гаиләгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, бала дөньяга килә. Әлбәттә, куаныч белән бергә, мәшәкатьләр дә өстәлә. Бәбине гел карап, тәрбияләп үстерәсе була. Ул борчыла да, елап та ала. Менә шул чакта әниләребез бишек җырларын көйләп, җырлап йоклаталар, юаталар. Халкыбызда бишек җырлары борын-борын заманнарда ук барлыкка килгән. Балалар сөйләшә белмәсә дә, шул авазларны тыңлап яткан, шулай рәхәтләнеп йоклап сөйләшә .(Бала елаган тавыш)
Талгын гына “Бишек җыры”( Габдулла Тукай шигыре, Татар халык көе) ишетелә.
Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла, угълым, йом күзен,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.
Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сина теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.
Гыйzzәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!
-Ишетәсезме, нинди моңлы җыр ишетелә. Сезнең мондый җыр ишеткәнегез бармы?
-Балалар, бу бишек җыры. Бишек җырлары, гадәттә, баланы бишектә тирбәтеп йоклатканда көйләнә. Бишек тирбәткәндә килеп чыккан әлеге җырларны бишек җырлары дип йөртә башлаганнар.

Тәрбияче бишек белән таныштыра.
-Бишек электән ук табигый материаллардан хәзерләнгән. Бишекне миләш агачыннан ясарга тырышканнар, чөнки ул сыгылмалы агач, сынмаган.Әле аның шундый ырымы да булган: бишекне җимешләре күп булган агачтан ясарга кушканнар. Ягы-ягы тал чыбыктан үрелгәннәре да очрый, күбрәк балалар тусын өчен, бишекне тал агачыннан да үргәннәр.Тар гына такта кисәкләрен бизәкләп ясаганнарын да очратырга мөмкин. Бишекне дүрт тактадан рамка кебек озынча итеп эшлиләр . Аның төбенә нык тукыма тегеп куялар. Бишек сиртмә ярдәмендә ыргакка эләгә һәм түшәмгә ныклы итеп беркетелә. Бишекне әнисенең караваты янына асып куялар. Аларга әнкәйләрнең моңнары сеңгән, теләкләре уралган.
-Ә менә бишекләрне бүген очратып буламы соң? Бишекләр инде өйләрдә юк диярлек, аларны заманча бишек –коляскалар алыштырды.
-Балалар, сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы? Чыбылдык ни өчен кирәк булган икән соң?
(чыбылдык күрсәтелә)
Чыбылдык ул – бишек өстенә каплап куела торган тукыма. Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Бәби рәхәтләнеп йоклый.
Тәрбияче: (Курчакны тотып) Бәбине алып кайткач ,аңа исем кушалар. Балага әти –әни , дәү әни, дәү әти исем эзли башлыйлар. Аннан бер фикергә килгәч, балага иң матур исем тапкач, мулла чакыртып исем кушалар. Әйдәгез без дә бу нәни курчагыбызга исем сайлыйк әле.
-Балалар һәрберсе татар исеме әйтеп чыга.(бер фикергә киләләр)
-Димәк, без бу курчакка Алсу дип исем кушабыз. Сез барыгыз да ризамы?
-Әйе, риза.
-Баланы кыйбла тарафына яткызып уң колагына исем әйтәләр, синең исемең Алсу була, аннан азан әйтелә. Менә хәзер безгә Булат азан әйтеп күрсәтер.
Булат: Аллаху акбар, Аллаху акбар,
Аллаху акбар, Аллаху акбар
Ашхаду алла илаха илла ллах.
Ашхаду алла илаха илла ллах.
Ашхаду анна Мухаммада-р-расулуллах.
Ашхаду анна Мухаммада-р-расулуллах.
Хаййа ‘ала ссалят (х)!
Хаййа ‘ала ссалят (х)!
Хаййа ‘алал фалах!
Хаййа ‘алал фалах!
Аллаху акбар, Аллаху акбар.
Ла илаха илла ллах!
Тәрбияче:Менә курчакка Алсу дигән исем дә куштык.
-Ана бишек җыры җырлаганда сабыена үзенең изге теләкләрен тели. Бишек җырлары тыңлаган сабый тыныч холыклы булып үсә. Бала елаганда да, ана сабыйны бишек җыры көйләп юата. Ул сөйләшә белмәсә дә, сүзләрне аңламаса да бала җырны тыңлап изрәп йокыга киткән.
-Балалар, сезгә әниләрегез бишек җыры җырлыймы? ( балалар җырлап күрсәтәләр)
Куанычларым, шатлыгым булып,
Балам, багалмам, үсәрсеңме син?
Сагынып җырлар җырыма минем,
Күземнең нуры күчәрсеңме син?
Бәхет гөлемнең чәчәге булып,
Былбыл кошкаем яшәрсеңме син?
Әнием диеп, кадерлем диеп

Сандугачкаем дәшәрсеңме син?
- Балалар, ишеттегезме, бишек җырында әнисе сабыена нинди матур сүзләр белән эндәшә?
-Дөрес, балалар, әни баласына бары тик матур, назлы сүзләр белән генә эндәшә: алсу алмам, бердәнберем, терәгем, алтыным, бәхетем, күз нурым, бәхет йолдызым.
- Ә сезгә әниләрегез нинди ягымлы сүзләр әйтә соң? Әйдәгез, без моны белү өчен "Ягымлы сүзләр"уенын уйнап алабыз. Бишек җыры башлануга бер-беребезгә курчакны тапшырабыз. Көй туктагач, кемдә курчак кала, шул ягымлы сүз әйтә.
-Балалар, сезнең курчакларыгыз да бик арыганнар түгелме соң, аларны йоклатырга кирәк. Элек заманда бала тугач та, аны ак биләүгә биләгәннәр . Без дә сезнең белән курчакларыбызны бәби итеп биләргә өйрәндек. Әйдәгез сынап карыйк әле, кем үзенең курчагын матур итеп биләр икән?
Тәрбияче. Әйдәгез бергәләшеп бишек җырын тыңлыйк.
Шакирова Камилә башкаруында "Бишек җыры".
ЭНЕСЕНӘ УЛ АПА Мөнир Мазунов шигыре
Җырлый-җырлый кыз бала
Энекәшен йоклата,
Биштә генә булса да,
Энесенә ул апа.
Әлли-бәлли бәй итә,
Энем йокыга китә.
Әнкәй, мәми пешереп,
Әткәйне эштән көтә.
Кошлар кунган тирәккә,
Аларны җил тибрәтә.
Тышта җилләр искәндә,
Бәби йоклый мендәрдә.
Әлли-бәлли бәй итә,
Энем йокыга китә.
Йоклатканга энемне,
Әнкәй мине пәп итә.
Йоклый бала, төш күрә,
Көлә, күккә сикерә,
Имеш, аны әтисе
Үсти-үсти иттерә.
Әлли-бәлли бәй итә,
Энем йокыга китә.
Энем йокыга киткәч,
Әни бераз ял итә.
-Балалар, безнең курчакларыбыз йокыга да киттеләр. Алар тынычлап йокласыннар.
Тәрбияче: Балалар сезгә шөгыль ошадымы? Сез бүгенге шөгыль турында кемнәргә сөйләргә телисез? Сез балалар бүген бик тапкыр, игътибарлы булдыгыз. Мин сезнең белән горурланам. Әфәрин,булдырдыгыз балалар.

Файдаланылган әдәбият:
1.К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, Г.М.Сафиуллина - Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе:методик кулланма, Казан,2013
2. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия.-Казан: РИЦ,2011

**Базгутдинова Гульчачак Рашитовна**
**воспитатель МБДОУ «Детский сад общеразвивающего вида №6 «Радуга» Кукморского муниципального района РТ**

## Колыбельные песни в «Сказке о глупом мышонке»

Конспект образовательной деятельности по развитию речи

**Цель:** обогащать и активизировать словарный запас посредством участия в словесно-речевых играх.

**Задачи:** совершенствовать навыки коммуникативного общения, словоизменения словообразования; упражнять в употреблении наречий; развивать диалогическую связную речь, образное представление; расширять словарный запас через участие в словесно – речевых играх; воспитание в детях добрых чувств, сопереживания в сложившейся ситуации

**Методические приемы:** словесные; наглядные; практические.

**Материалы и оборудование:** презентация; кукла.

**Ход:**

**Организационное начало**

**Вступительная беседа**

- Ребята, тему нашего занятия вы должны угадать сами. Посмотрите, на слайде вы видите картинки (колыбелька, ребенок, мама, спальня). О чем мы будет говорить?
- Правильно, про колыбельные песни
- Колыбельные песни сопровождают человека всю жизнь: сначала их поют малышу, а, повзрослев, он поет их своим детям. Они появились давно и будут существовать вечно. Все или почти все дети слушали их от своих мам, бабушек и нянь. Под звуки колыбельной малыш засыпает, погружаясь в мир сновидений.

Еще наши предки заметили, что при монотонном покачивании малыш быстро затихает, успокаивается и засыпает. Для того, чтобы малыш быстрее засыпал, была придумана специальная кроватка для укачивания – колыбелька (зыбка), а песни, под которые малыш засыпал, назвали колыбельными.

Колыбель разные народы называли по разному: зыбка, люлька, качалка, баюкалка, колыска, колыбелька, бишек и т.д. Изготавливалась она из самых разнообразных материалов: дерева, ивовых прутьев, ротанга, кожи, коры, веревок. Колыбель подвешивали к гибкому шесту на потолке, снизу прикреплялась веревка, которая позволяла взрослому качать эту колыбель с находящимся в ней ребенком, не отвлекаясь от повседневной домашней работы.

- Давайте с вами вспомним «Сказка о глупом мышонке», в сказке каждый пел колыбельную мышонку *(работа с презентацией)*

Как пела мама мышка
- Спи, мышонок, замолчи!
Дам тебе я хлебной корки
И огарочек свечи.
- Как пела утка?
- Га-га-га, усни, малютка!
После дождика в саду
Червяка тебе найду.
- Как пела жаба?
- Ква-ква-ква, не надо плакать!
Спи, мышонок, до утра,
Дам тебе я комара.
- Как пела мама лошадка?
- И-го-го!
- Спи, мышонок, сладко-сладко,

Повернись на правый бок,
Дам овса тебе мешок!
- Как пела мама свинка?
- Баю-баюшки, хрю-хрю.
Успокойся, говорю.
- Как пела курица?
- Куд-куда! Не бойся, детка!
Забирайся под крыло:
Там и тихо, и тепло.
- Как пела мама щука?
(она ничего не пела)
- Как пела маму кошка?
- Мяу-мяу, спи, мой крошка!
Мяу-мяу, ляжем спать,
Мяу-мяу, на кровать.
- Ребята, у каждого мама – одна. И для каждого из нас она самая лучшая. Всегда помните и знайте об этом. А как поступил мышонок? Правильно ли он сделал?

**3. Прослушивание колыбельных песен разных народов**

- Давайте мы с вами послушаем колыбельные песенки. Какие чувства просыпаются в вашей душе, когда слушаете колыбельные? (*Задушевность, сердечность*, доброта и теплота)
- А сейчас, кто хочет исполнить свою песню и убаюкать эту крошку? (Детям предлагается сесть на стул и спеть колыбельную, укачивая куклу.)

**Физкультминутка**

- А теперь просыпайтесь. Мы с вами сделаем зарядку
Потягу-потягунюшки,
Порасту- порастунюшки,
Ножки-ходунюшки,
Ручки-хватунюшки,
В роток-говорок,
А в голову разумок.
Водичка, водичка,
Умой мое личико,
Чтобы щечки горели,
Чтобы глазки блестели,
Чтоб смеялся роток,
Чтоб кусался зубок.

**Игра «Эмоции»**

- Ребята, мы с вами сейчас поиграем. Мы повторили как пели колыбельную животные со сказки, а теперь мы это разыграем
- Как пела песню мышка? (слишком тонко, пи-пи-пи)
- Как пела песню утка? (слишком громко, га-га-га)
- Как пела песню жаба? (слишком скучно, ква-ква-ква)
- Как пела песню лошадка? (слишком страшно, го-го-го)
- Как пела песню свинка? (слишком грубо, хрю-хрю-хрю)
- Как пела песню курица? (слишком нехорошо, ко-ко-ко)
- Как пела песню щука? (слишком тихо)
- Как пела песню кошка? (слишком сладко, мяу-мяу-мяу)

**6. Подведение итогов**

Дети встают в круг и кладут руки на плечи друг другу. Они приветливо смотрят друг на друга и говорят: «Спасибо за приятное занятие!».

**Каюмова Зульфира Илдусовна**
**МБДОУ “Детский сад с.Туембаш”**
**Кукморский муниципальный район РТ**

## БИШЕК ҖЫРЛАРЫ-ХАЛКЫБЫЗ РУХЫНДА

Максат:
1. Балаларны халкыбызның йөрәк түреннән чыккан җәүһәрләре – бишек җырлары белән таныштыру;
2. Бишек җырларның эчтәлеген һәм тәрбияви үзенчәлекләрен ачыклау;
3. Әти - әнигә, әби-бабайларыбызга һәм моңлы бишек җырларына мәхәббәт тәрбияләү.
Үстерү бурычлары: сүзлек байлыгын арттыру, хәтерен, игътибарын, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
Тәрбия бирү бурычлары: татар халкының гореф-гадәтләренә ихтирам тәрбияләү.
Белем бирү бурычлары: балаларны бишек җырлары белән таныштыруны дәвам итү
Төп белем бирү өлкәсе: танып-белү
Әлли-бәлли итәр бу
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла ,углым ,йом күзең,
Йом-йом күзең , йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Елап үтә көндезең.
Гыйzzәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!(Г.Тукай “Бишек җыры”)
Бишек җырлары белән таныштыру.
Аларны кем иҗат иткән?
Бишек җырлары татар халык авыз иҗатының бер төре. Бу әсәрләр моннан берничә гасыр элек барлыкка килгән. Аларның иҗатчысы-татар милләтенең сәләтле кешеләре. Билгеле, гасырлар узу белән аларның эчтәлеге камилләшә барган.
Туган телемдәге бишек җырларының барлыкка килү тарихы.
Бишек җырлары - татар халык авыз иҗатының иң борынгы төрләреннән берсе. Бу әсәрләр моннан берничә гасыр элек барлыкка килгән. Аларның иҗатчысы татар милләтенең сәләтле кешеләре. Бу җырларның төп максаты - баланы тынычландырып йоклату. Борынгы заманнарда баланы тирбәтеп йоклату өчен махсус җайланма- бишек кулланылган. Әбием сөйләве буенча, безнең якларда бишекне дүрт рамка кебек агачтан, озынча итеп эшләгәннәр. Аның төбенә капчык чүпрәген тегеп куйганнар. Дүрт почмактан бау бәйләп ыргакка бәйләгәннәр. Түшәмгә махсус божра куеп, шуңа ыргак белән бишекне әнисенең кровате янына асып куйганнар. Юкәдән һәм ящиктан ясалган бишекләр дә кулланылышта булган. Әниләр, әбиләр, бала караучы үсмерләр, бишек кырыена утырып, моңлы итеп җыр сузганнар,тирбәтеп, баланы йоклатканнар. Шулай итеп бишек җырлары барлыкка килгән.
Халык авыз иҗаты әсәрләренең бер төре булган - бишек җырларының башкаручылары, төзелеше, үзенчәлекләре.
Бишек җырының төп башкаручылары – өлкәннәр. Барыннан да элек, бу җыр халыкның дөньяга карашын, бигрәк тә хатын- кызның күңел торышын, рухи дөньясын чагылдыра. Бишек җырларының төп темасы , ананың хыяллары белән бәйләнгән. Ул - баланың бәхетле, таза, сәламәт һәм укымышлы булуын теләү. Күп очракта фикер дога , теләк булып та формалашкан. Шушында ук ана кеше эчке кичерешләре, теләкләре салынган

жыр аша яхшылык һәм явызлык төшенчәләрен дә кертеп, беренче укытучы, әдәп-әхлак, эстетик зәвык формалаштыру юнәлешендә беренче тәрбияче була. Ана ул җырларны бөтен күңелен биреп, баласын назлап, яратып, иркәләп җырлый. Бу вакытта аның теле белән берсеннән - берсе матур сүзләр әйтелә: « йолдызым», «кадерлем», «йөрәк бәгърем», «куанычым», «шатлыгым», «таң йолдызым», «атлык җырым», «бәбкәем».
Бишек җырлары – йоклату чарасы гына түгел, ул- саклаучы да. Элек заманнарда Себердә яшәүче татар, казах халыклары бишек җырларына аеруча игътибар , аерым мәгънә биргәннәр. Бу халыкларның гореф-гадәтләре буенча, һәр яңа туган сабыйга аерым бишек җыры багышланган. Аны әнисе иҗат иткән. Шул җыр аны гомер буе явыз көчләрдән, йокысызлыктан, авырулардан саклаган. Бу җырлар әкияткә охшаган, мәхәббәт, изгелек белән сугарылган.
Билгеле,гасырлар узу белән аларның эчтәлеге камилләшә барган.
*Борынгылар тикмәгә генә: “ Тәрбия бишектән башлана, бишектә кермәгән, бишектән төшкәч кермәс,” –димәгәннәр.*
Язучылар иҗатында бишек җырларының тоткан урыны.
Бишек җырларын ике төргә: халык җырлары, әдәби бишек җырларына аерып карап була. Халык бишек җырлары туган як моңнарын, милли моңнарны үзэченә ала. Анда бай, бәхетле тормыш, киләчәккә өметләр чагылдырыла. Автор җырлары исә, халык җырларына нигезләнеп язылган. Бала анда тирә- юнь белән таныша. Автор җырларының сүзләре дә катлаулырак , ритм һәм көйләүләр дә башкачарак, әмма ана назы зур урын алып тора.
Әдәби бишек җырлары Дәрдмәнд (Закир Рәмиев) “Бәллү”, Н. Думави (Нәҗип Тахтамышев), Г. Тукай “Бишек җыры”, М.Җәлил “Бишек янында” , Р.Вәлиева “Йокла , энем”, Р.Миңнуллин “Тал бишек” кебек әсәрләрендә урын алган.
Бишек җырларының бүгенге көндәге торышы һәм әһәмияте.
Кеше тормышында бишек җырларының урыны дәрәҗәле. Һәркем аны сабый чакның якты истәлеге итеп, гомеренең соңгы көннәренә кадәр күңел түрендә саклый. Ул җырлар газиз ана, туган тел, туган ил кебек изге төшенчәләр белән бергә йөри. Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү генә калган вакытта башкарыла. Әни кеше ул мәлдә күңеле белән баланың рухи дөньясына якынаерга, уй-фикерләрен нәниләр кабул итәрлек гади, самими итеп әйтергә омтыла. Аналарның бәгырьдән, йөрәк түреннән чыккан, ягымлы сүзләр белән ана телендә яңгыраган бишек җырлары тәрбиядә башка бернинди чара белән чагыштырырлык һәм алмаштырырлык түгел. Бала әнисен тыңлап, аңа кушылып җырларга, үсә төшкәч, җыр сүзләрен кабатларга тели. Шулай итеп, бишек җырлары аша, сабый туган телендә сүзләрне әйтергә, тирә-якны танып белергә, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерергә өйрәнә, үзе дә сүзләрне әйтергә омтыла.
Мәсәлән, безнең кызлар үзләре яраткан курчакларын бишек җырларын җырлап “йоклаталар ”. Кыз балалар өйдә курчак белән “бала караучы” булып уйнаганда да алардан еш файдаланалар. Музыка дәресләрендә дә бишек җырларын бик яратып башкарабыз.
Аларның гаҗәеп бер үзенчәлеге бар: алар, артык вәгазь укымыйча гына, баланы ничек яшәргә, кешеләргә ихтирамлы, мәрхәмәтле булырга, ата-ананы, туганнарны хөрмәт итәргә һәм башка күркәм сыйфатларга ия булырга өйрәтәләр. Менә ананың сабыена тели торган шул сүзләре:

*Имәндәй нык бул,*
*Чыршыдай биек бул*
*Каендай ак бул,*
*Чишмәдәй саф бул.*

Күренгәнчә, әлеге бишек җырларының беренче юлларында ук ана үзенең баласының сәламәт, әхлакый саф булып үсүен тели. Аннары ул җырны болай дәвам итә:

*Ата-аналы бул,*
*Алтын канатлы бул,*
*Бай дәүләтле бул.*
Тормыш итү өчен кирәкле әйберләр булдырып, кайгы-хәсрәт күрмичә,
эти-әниең белән бергә яшәргә язсын. Бу юлларның төп мәгънәсе шунда.
Бишек җырларының алдагы юлларында ана баласында туган телне,
халык иҗатын ихтирам итү, табигатькә сакчыл карау хисе тәрбияли:
*Бүләк итәм, балам, туган телеңне...*
*Күңелемә туган олы хисләрне,*
*Чылтыр чишмәне, алсу иртәне,*
*Әкият тулы айлы кичләрне...*
Күп кенә бишек җырларына кош-корт, хайван образлары да килеп кергән. Шулар арасыннан песи - балага аеруча якын,таныш җан иясе. Ул баланы тирбәтә, мияулап йоклата, күчтәнәчләр алып килә.
Мәсәлән,
*Бәү-бәү итик, әйдә йоклыйк*
*Улым,улкаем,*
*Песиең дә арды әнә*
*Боегып калды.*
*Башын салып тәпиенә*
*Йокыга талды.*
Галимнәр инде күптән ачыклаган: балага белем һәм тәрбия бирүдә бишек җырлары бик зур роль уйный. Алар сабыйның тыныч холыклы булып үсүенә ярдәм итә. Әнисенең җырлары аша ул туган телендә сүзләр әйтергә, тирә-якны танып белергә, фикерләү сәләтен, сөйләмен үстерергә өйрәнә.
Бишек җыры....Никадәр йөрәк түреннән чыккан ягымлы сүзләр,иксез- чиксез матур хыяллар,берни белән дә чагыштырып булмаслык ана мәхәббәте күңелләрнең иң нечкә кылларын тибрәндерерлек моң булып агыла да агыла...
Мин тууга әнием мине бишек җырлары белән тибрәтеп йоклаткан,елаганда тагын бишек җырларын җырлап юаткан.
*Әлли-бәлли: йом син күзең,*
*Әлли-бәлли — татлы сүзем.*
*Йоклый инде бөтен бәбиләр дә,*
*Йоклый инде хәтта әбиләр дә*
*Әлли-бәлли, йом син күзең,*
*Әлли-бәлли, татлы сүзем.*

Балалар бакчасына йөргәндә дә , мәктәптә уку дәресләрендә дә без бишек җырлары белән таныштык, аны өйрәнүне һаман дәвам итәбез.
Минем максатым- бишек җырлары турында күбрәк белү, аларның килеп чыгышын өйрәнү,авторлары турында мәгълүмат туплау.
Бишек җырлары- дөньядагы иң татлы, иң ләззәтле җырлар ул. Чөнки без бишектә ятканда ук ул җырларны ишетеп, күңелебезгә сеңдереп үсәбез. Әнкәбезнең ягымлы тавышы белән халкыбызның милли моңнары безнең күңелләребезне эретә. Бишек җырлары һәркемгә кадерле, чөнки алар балачакны хәтерләтә.
Бишек җырларының *төп вазифасы*- бишек тирбәтү, баланы йоклату, тынычландыру. Гаиләгә бәхет, шатлык,өмет-куанычлар өстәп бала дөньяга килә. Әлбәттә куаныч белән бергә мәшәкатьләр дә өстәлә.Бала борчыла да,елап та ала. Шул вакытта әниләребез бишек җырлары җырлап аларны юаталар.
Безнең халкыбызда бишек җырлары бик борынгыдан барлыкка килгән. Аны әбиләребез,әниләребез,апа-сеңелләребез үзләре уйлап чыгарган.Шул җырлар безгә дә буыннан буынга күчеп килеп җиткән. Бишек җырлары халык җырлары белән бер үк вакытта барлыкка килгән дип карала. Алар инде моннан мең еллар элек тә яшәгәннәр.

Салмак кына агылучы моңлы аваз сабыйны тынычландырган. Ул сөйләшә белмәсә дә, сүзләрне аңламаса да җырны тыңлап изрәп йокыга киткән. Ана теле иң беренче балага бишек җыры аша үтеп кергән.
Бу җырлар ни өчен бишек җырлары дип атала соң? Бу да безнең тарихыбызга барып тоташа. Борынгы бабаларыбыз яңа туган сабыйны тирбәтү өчен махсус җайланма уйлап тапканнар .Ул “бишек” дип аталган.
Ә аларның ниндиләре генә булмаган! Нечкә тал чыбыгыннан үрелгәннәре дә,агачны уеп ясалганнары да, тактада сырлап эшләнгәннәре дә... Биредә горур, уңган этиләребезнең,газиз бабаларыбызның матурлык белән бергә үрелгән өметләре, һөнәргә осталыклары,рухи дөньялары чагыла.
*Бездә бишек әллә ничек*
*Талдан, җырдан үреләә.*
*Җылы бишек, җырлы бишек*
*Эленә өй түренә.*
*Ничек җырламасын бишек*
*Сөн талларыннан үр дә!*
*Талбишектә үстем мин дә*
*Сизелмимени бер дә?!*
Шушы бишекне тирбәтеп әниләребез, әбиләребез җырлар җырлаганнар.
Бишек тирбәткәндә килеп чыккан әлеге җырларны бишек җырлары дип йөртә башлаганнар.
“Әлли-бәлли бәү” . Әлеге юллар һәрбер бишек җырында кабатлана. Ул җырның сүзләре һәм көйне үзара бәйләүче күпер ролен үти
Кем тарафыннан һәм кайчан иҗат ителүенә карап бишек җырларын халык бишек җырлары(борынгы җырлар) һәм авторлар тарафыннан иҗат ителгән бишек җырларына бүлеп карарга мөмкин.
Борынгыдан килгән халык җырларына салынган фикер мәгънәви яктан бер-берсеннән аерыла.
*Әлли-бәлли итәр бу,*
*Йокыларга китәр бу,*
*Бәү-бәү итеп, күз йомып,*
*Изрәп кенә китәр бу.*
*Алма кебек тәгәрәп,*
*Үсеп буйга җитәр бу,*
*Абыйлары артыннан*
*Мәдрәсәгә китәр бу.*
*Мәдрәсәләрдә укыгач,*
*Галим булып җитәр бу.*
Әлеге җырда әни кешенең якты өметләре, ныклы ышанычлары,баласын рухи һәм физик яктан матур,сәламәт.акыллы итеп күрү теләге ята.
*Әтисенә ай кебек,*
*Әнисенә көн кебек,*
*Килеп киткән кешегә*
*Кадерлеге юк кебек.*
Бу җырда без сабыйны һәркемгә кадерле газиз бер бала буларак күрәбез. Аның янында һәрвакыт якларга, сакларга әзер торучы яраткан әти- әнисе бар.
“Йөрәк маем, алтыным, күз нурым, күгәрченем, йолдызым ” кебек иркәләү сүзләре бик күп бишек җырларында кабатлана.
Авторлары онытылган халыкныкы булып киткән бишек җырларыннан тыш күренекле шагыйрьләребез иҗат иткән бишек җырлары да бик күп.Борынгы чор шагыйрьлщреннән башлап бүгенге көн әдипләребезгә кадәр әлеге тема белән кызыксынып үзләренең матур бишек җырларын иҗат иткәннәр. Итмичә соң! Алар да бишектә тирбәлеп әниләренең

бишек җырларын тыңлап үскәннәр бит.
*Кыйгач кашым,*
*Асыл ташым!*
*Йоклаек икәү!*
*Йокла, иркә,*
*Йокла, бәбкә,*
*Бәүкәй, бәллү-бәү!*
*Хублар хубы,*
*Алма тубы,*
*Пешкән, тулгансын,*
*Бу чагында*
*Син тагын да*
*Чибәр булгансын!*
*Алмакаем,*
*Аппакаем,*
*Йоклаек икәү!*
*Йокла, иркә,*
*Йокла, бәбкә,*
*Бәүкәй, бәллү-бәү!*
Дәрдмәнднең "Бәллү" дигән әлеге шигырендә 14 төрле иркәләү сүзе бар.( Кыйгач кашым,асыл ташым, иркә, бәбкә, хублар хубы, алма тубы,алмакаем, аппакаем, гөлкәем, сөнбелкәем, колынкаем, җанкаем, бөдрәкәй, фәрештәкәй. Бу җыр аркылы без халкыбызның тел мирасының никадәр бай икәнен күрәбез.
Бөек Тукаебыз язган "Бишек җыры"нда баланы укымышлы ,акыллы галим итеп күрү теләге ята. Аның җырында "йолдызым, бәгырем, гыйззәтем, кадерем, куанычым, шатлыгым" кебек иркәләү, назлау сүзләре урын алган.
Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син,
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!
М.Җәлил үзенең кызы Чулпанга багышлап язган бишек җырында "таң йолдызым, шатлык җырым ,шаян кызым" кебек ягымлы сүзләрне куллана.
*Шаян кызым син минем,*
*Таң йолдызым син минем,*
*Йөрәгемдә кабынган*
*Шатлык җырым син минем.*
Бүгенге көн әдипләреннән Г.Афзалның Әлли-бәлли, былбылым" бишек җырында да сабыйны "бал-шикәр,ай нуры. Былыбылым, күз нуры" кебек матур сүзләр белән иркәли.
*Бал-шикәрдән тәмлесең,*
*Күр төшеңнең тәмлесен,*
*Ак көмештәй ай нурым,*
*Әлли-бәлли, былбылым.*
*Әлли-бәлли, әлли-бәлли,*
*Әлли-бәлли, былбылым!*

Бишек җырларын тыңлаганнан соң мин шундый фикергә килдем: Нинди генә бишек җырларын алып карасак та халыкныкымы ул, яки авторлар тарафыннан иҗат ителгәнме аларның һәркайсында әйтергә теләгән бер фикер ята: бу баланың киләчәгенә якты өметләр

баглау, аны авырлыклардан яклау һәм саклау теләге, сабый өчен җылы һәм уңайлы мохит тудыру, аны шул тирәлектә иркәләп, назлап үстерү теләге.
Берьюлы шулкадәр ягымлы, матур сүзләрне бары тик бишек җырларында гына табарга мөмкин дигән фикергә килдем мин.
Бишек җырлары аша баланың күңел күзләре ачыла, матурлыкны моңны таный башлый. Һәркем бу гүзәл чыганакны, сабый чагының якты истәлеге итеп күңел түрендә саклый. Шул бишек җырлары аша бала тәүге кат шигъри матурлык, аналарның йөрәк җылысы, үз халкының рухы белән очраша. Кеше ничә яшендә булуына карамастан, бу моңлы, тыныч, салмак. Назлы, ягымлы көйне ишетү белән үзенең аллы-гөлле чәчәкләргә төренгән балачак бакчасына әйләнеп кайта. Һәм үзе дә сизмәстән бишек җыры көйли башлый. Кечкенә вакытта, курчаклы уйнаганда, аларны «ә-ә-ә итә» дип, үзебезчә йоклаткандай итә идек. Димәк, әниләребез сөйләгән сүзләр, җырлаган җырлар безгә тулысынча аңлашылып бетмәсә дә, беркадәресе аңсыз рәвештә булса да безнең зиһенебездә, күңелебездә барыбер сакланып калган.
Әниләребез безгә бишек җырларында үзләренең киләчәккә булган өметләрен салалар.Һәр сабыйның тормыш белән очрашуы бишек җырыннан башлана. Бишек җыры аны олы җиһанга чыгара. Халкыбызга кирәк, бик кирәк бишек җырлары. Бу моң һәр өйнең ишеген кагардай булсын. Бишекләрдән бишекләргә күчеп, өй түрендә урын алырдай булсын. Безне балачагыбызга алып кайтсын. Әниләребезнең йокысыз төннәрен,әтиләребезнең сагынып эштән кайткан минутларын.әбиләребезнең безне яратып сөйгән йомшак кулларын искә төшереп торсын һәм бу кадерле кешеләребезгә карата булган якты хисләребез мәңге сүрелмәсен. Бишек җырлары белән бергә үрелеп барсын.
*Әнкәемнең җырын тыңлап*
*Тал бишектә үскәнмен*
*Шул җыр белән канатланып*
*Тәпи атлап киткәнмен.*
*Бишек җыры илһам биргән*
*Юлдаш булган җаныма.*
*Әнкәемнең нурлы йөзе*
*Мәңгегә күз алдымда.*
*Бишек җыры белән иңгән*
*Күңелемә яктылык, —*
*Туган җирне һәм гомерне*
*Сөю хисе саф булып.*

Йомгаклау: Бишек җырларын тыңлаганнан соң мин шундый фикергә килдем: Нинди генә бишек җырларын алып карасак та халыкныкымы ул, яки авторлар тарафыннан иҗат ителгәнме аларның һәркайсында әйтергә теләгән бер фикер ята: бу баланың киләчәгенә якты өметләр баглау, аны авырлыклардан яклау һәм саклау теләге, сабый өчен җылы һәм уңайлы мохит тудыру, аны шул тирәлектә иркәләп, назлап үстерү теләге.
Берьюлы шулкадәр ягымлы, матур сүзләрне бары тик бишек җырларында гына табарга мөмкин дигән фикергә килдем мин.
Бишек җырлары аша баланың күңел күзләре ачыла, матурлыкны моңны таный башлый. Һәркем бу гүзәл чыганакны, сабый чагының якты истәлеге итеп күңел түрендә саклый. Шул бишек җырлары аша бала тәүге кат шигъри матурлык, аналарның йөрәк җылысы, үз халкының рухы белән очраша. Кеше ничә яшендә булуына карамастан, бу моңлы, тыныч, салмак. Назлы, ягымлы көйне ишетү белән үзенең аллы-гөлле чәчәкләргә төренгән балачак бакчасына әйләнеп кайта. Һәм үзе дә сизмәстән бишек җыры көйли башлый. Кечкенә вакытта, курчаклы уйнаганда, аларны «ә-ә-ә итә» дип, үзебезчә йоклаткандай итә идек. Димәк, әниләребез сөйләгән сүзләр, җырлаган җырлар безгә тулысынча аңлашылып бетмәсә дә, беркадәресе аңсыз рәвештә булса да безнең зиһенебездә, күңелебездә барыбер сакланып калган

Алсу Хисамиева – Бишек җыры
Үземнең кызым син, күземнең нуры син,
Үземнең кызым син, күземнең нуры син.
Яз кояшым, таң йолдызым, син чәчәкләргә тиң,
Яз кояшым, таң йолдызым, син чәчәкләргә тиң.
Минем кызым, тәүге җырым,
Яз кояшым, таң йолдызым, син чәчәкләргә тиң.
Син еласаң, балам, кошлар тынып кала,
Син еласаң, балам, кошлар тынып кала,
Чишмә челтрәп ага-ага, сиңа җыр чыгыра,
Чишмә челтрәп ага-ага, сиңа җыр чыгыра.
Минем кызым, минем балам,
Чишмә челтрәп ага-ага, сиңа җыр чыгыра.
Кашың кыйгач, кара, күзең йомылып бара,
Кашың кыйгач, кара, күзең йомылып бара
Матур төшләр күрә-күрә, йокла газиз бала.
Матур төшләр күрә-күрә, йокла газиз бала.
Минем кызым, минем җырым,
Матур төшләр күрә-күрә, йокла газиз бала,
Матур төшләр күрә-күрә, йокла газиз бала.
Йокла газиз бала, йокла газиз бала.

**Хасанова Римма, воспитатель**
**МБДОУ «Детский сад №5 «Созвездие»**
**Кукморского муниципального района РТ**

## Знакомство с колыбелью

Конспект образовательной деятельности для детей средней группы

**Программное содержание:**
Познакомить детей с разновидностями колыбелек (из дерева, плетеные из луба, из ивовых прутьев). Дать представление о жизни в старину, русском быте, старинных семейных обычаях, связанных с рождением ребенка, закреплять знания старинных русских имен. Активизировать речь детей следующми существительными: «колыбелька», «зыбка», определениями: «старинный», «деревянный», «расписной», «узорчатый». Развивать внимание, память, мышление. Воспитывать уважение, интерес к обычаям старины, к русскому фольклору.
**Материалы и оборудование:**Русский народный костюм для воспитателя, атрибуты русской избы (русская печка, сундук, самовар, веник, сушки, баранки, хлебница), элементы русской народной одежды (платок, сарафан, рубаха, картуз, кокошник), кукла, люлька, уголёк, зернышки, монетки, картинки с изображением разновидностей люлек, тряпичные куклы по количеству детей.

**Ход:**

*Воспитатель, одетый в старинный русский сарафан входит в группу со словами:*
Добрый день, ребятушки!
Подойдите, не стесняйтесь.
Поудобней располагайтесь.
Всем ли видно, всем ли слышно,
Всем ли места хватило?
*Дети встают вокруг воспитателя. Воспитатель обращает внимание на свой наряд.*
Воспитатель: Ребята, посмотрите, какая я нарядная. Скажите, а что на мне надето? (Ответы детей.) Правильно, сарафан. Как вы думаете, почему сейчас не носят такую одежду? (Ответы детей). Когда ее носили? (Ответы детей). В прошлом веке, в старину.

Сегодня я вам предлагаю отправиться в прошлый век посмотреть, как жили люди раньше. Я скажу волшебные слова, а вы внимательно слушайте и повторяйте за мной:
Влево, вправо повернись,
В прошлом веке очутись!
Вот мы и попали с вами в прошлый век, в русскую деревню. Посмотрите, какие старинные предметы находятся в русской избе. *Рассматривание детьми предметов быта русской избы.*
*Воспитатель обращает внимание на стоящий в углу сундучок.*
Что это за странный сундучок?
И закрыт он на замок.
Если ключик подберем,
В нем сюрпризы мы найдем!
А чтобы сундучок открылся, нужно потрудиться - отгадать загадку. Слушайте внимательно.
Вам известен молодец,
Без которого жилец,
Хоть и знает, где живёт,
А в свой дом не попадёт? (ключ)
Воспитатель: Молодцы, ребята! Правильно отгадали загадки, и сундучок наш открылся.
*Воспитатель достает из сундучка элементы русской народной одежды (платок, сарафан, рубаха, картуз, кокошник). При этом называя вещи, дети помогают. Предложить детям нарядившись, посмотреться в зеркало.*
Воспитатель: Прислушайтесь, ребята, кажется, кто- то плачет. Кто бы это мог быть? Давайте посмотрим. *Дети и воспитатель подходят к люльке.*
Кто это у нас плачет,
Не получит калачик,
Кто это у нас ревет,
Не получит сухарек.
*Воспитатель берет куклу на руки.*

Мы поскачем-скачем-скачем,
Скачем на лошадке!
Мы давным-давно не плачем,
Все у нас в порядке!

*Достает из колыбельки куклу.*
Воспитатель: Ребята посмотрите, вот кто у нас плачет - малыш. *Ребенок достает куклу, качает.*
Воспитатель: С давних времен, когда ребенок рождается, родители ему придумывают имя. А какие вы знаете старинные имена? (Ответы детей) (Илья, Данил, Егор, Алёна, Фрося, Глаша.)
Воспитатель: Нашего малыша зовут Егорушкой. Это имя обозначает хозяин земли. Родители, когда называли его таким именем, хотели, чтобы, когда Егорушка вырастет, у него было много-много земли, и чтобы он был богатым и счастливым. Ребята, посмотрите, здесь для Егорушки приготовлены вещи, что же это? *Ребенок показывает: уголек, зернышко, монетки.*
Воспитатель: А кто знает. Зачем нашему Егорушке эти вещи? (Ответы детей) (Их клали, когда купали)
Воспитатель: Да. Правильно. Раньше, на Руси, давным-давно, во времена наших прабабушек и прадедушек эти вещи клали в таз с водой, когда ребеночка в первый раз купали. А что говорили когда клали уголек? Р*ебенок кладет в таз уголек.* (Привыкай к домашнему теплу). А что говорили, когда клали монетку? (Будь всегда богат). А что говорили, когда клали зернышки? (Будь всегда сыт).

Воспитатель: Ребята, пока наш Егорушка успокоился мы с вами поиграем.
Воспитатель вместе с детьми показывает движения, при этом произнося слова:
На кота - потягушки
На дитя - порастушки.
(Поочередное вытягивание рук вверх)
С гуся вода,
С дитя - вся худоба.
(Движения рук вверх и вниз с наклоном до пола)
Наденем сапожки
Это - с правой ножки,
Это - с левой ножки.
(Стоя, ноги врозь, поочередные наклоны к носкам ног.)
Топ-топ-топатушки!
Пляшут зайки на опушке.
Пляшут лапки и хвосты.
Что стоишь?
Пляши и ты!
(Прыжки: ноги врозь, ноги вместе.) *Игра проводится 2 раза.*
*Снова заплакала кукла.*
Воспитатель: Ребята, снова заплакал наш малыш. Как вы думаете, как помочь Егорушке успокоиться? (Ответы детей). Правильно, его надо положить в колыбельку и покачать.
*Дети вместе с воспитателем кладут куклу в колыбельку и качают.*
Воспитатель: Ребята, скажите, а где спит наш Егорушка? (Ответы детей) (В люльке, в колыбельке, в кроватке).
Воспитатель: Правильно, а ещё в старину колыбельку называли зыбкой. Зыбка - это люлька. Она легко качалась, "кланялась", как маленькая лодочка, плывущая по реке. Зыбки в крестьянских избах подвешивались на гибком месте - к потолку. Положит мама ребеночка в зыбку, качнет её раз - другой, а сама в это время пряжу прядет. Ребята, скажите, а из какого материала сделана зыбка? (Ответы детей).
Воспитатель: А ещё в старину зыбки делали из ивовых прутьев и плели из лыка.
*Дети рассматривают изображения зыбок.*
Воспитатель: А как вы думаете, кто в деревне делал зыбки? (Ответы детей). Посмотрите, на зыбке, какие красивые узоры. Как вы думаете, ребята, а зачем родители разрисовывали зыбки разными узорами? (Ответы детей).
Воспитатель: Ой, наш Егорушка снова заплакал. Как выдумаете, что надо сделать, чтобы Егорушка уснул? (Ответы детей). Правильно, ему надо спеть колыбельную песенку. Ребята, а как нужно спеть колыбельную песенку, чтобы Егорушка не испугался? (Ответы детей) (Тихим голосом, ласково).
*Воспитатель поет колыбельную:*

Ай, люли-люли-люли,
Прилетели журавли,
Прилетели журавли
— Сказку Егорке принесли.
Журавли-то мохноноги
Не нашли пути-дороги.
Они сели на ворота,
А ворота скрип-скрип.
Не будите у нас Егорку,
У нас Егорка спит-спит.

Воспитатель: Ну вот, кажется наш малыш, уснул. А в старинном сундучке есть для вас подарок. Я вам подарю маленьких кукол. В такие куклы играли крестьянские дети

давным-давно, в прошлом веке, очень давно. *Воспитатель раздает детям куклы и просит назвать их старинными именами.*
Воспитатель: Давайте покачаем их и споем им колыбельную песню:
*Дети садятся на коврик, укачивают кукол и поют:*

Спи, младенец мой прекрасный,
Баюшки-баю.
Тихо смотрит месяц ясный
В колыбель твою.
Стану сказывать я сказки,
Песенку спою;
Ты ж спи, закрывши глазки.
Баюшки-баю.

Воспитатель: Ну, вот и ваши детки уснули. А нам пора возвращаться в детский сад. Повторяйте за мной:
Влево, вправо повернись,
В детском саде очутись!
Вот мы и вернулись с вами в детский сад. Где мы с вами сегодня побывали? Что нового узнали? Что увидели? (Ответы детей).

**Гайфутдинова Алсу Айратовна**
**МБДОУ «Детский сад №6 «Радуга» г. Кукмор»**
**Кукморского муниципального района РТ**

## Знакомство с колыбельной песней

Конспект занятия в старшей группе

**Цель**: познакомить детей с колыбелью и колыбельными песнями.
**Задачи**:
1. Образовательные: знакомить со старинным предметом – «колыбелью»; заинтересовать в знакомстве с русским фольклором «колыбельные песни»; приобщать детей к духовной культуре русского народа.
2. Воспитывающие: воспитывать гуманные чувства; воспитывать любовь к ближнему, любовь к народной культуре.
3. Развивающие: развивать познавательный интерес к колыбельным песням, потешкам; развивать речь и мышление.
**Оборудование**: кукла Катя и куклы по количеству детей, кровать игрушечная, предметные картинки люлек и колыбелек.

### Ход ОД

1. Организационный момент
Воспитатель: Добрый день, детушки – касатушки.
Подойдите, не стесняйтесь
Поудобней располагайтесь
Всем ли видно, всем ли слышно
Всем ли места хватило *(дети строятся в круг возле воспитателя)*
Здравствуйте, ребята. Рада видеть вас у себя на занятии *(дети здороваются с воспитателем)*
2. Основная часть
Воспитатель: Дети, сегодня к нам в гости пришла кукла Катя, давайте поздороваемся с ней *(здороваются).* Ребята, Катя сегодня целый день играла и очень устала, она хочет спать. Давайте поможем Кате уснуть, споем ей песню. А какую песню нужно спеть малышу, чтобы он уснул? *(колыбельную).*
Правильно. Давайте споем Кате колыбельную песенку, чтобы она уснула *(выразительно и напевая читает стихотворение Г. Лагздынь, укачивая на руках куклу).*
Положу я Катеньку,

Дочку мою сладеньку,
На широкую кровать.
Надо Катеньке поспать!
Во простынка! Одеяло!
Вот подушка! Покрывало!
Из цветного плюша.
Не вертись, Катюша!
Спи!
Воспитатель: Ребята, а где Катя будет спать? *(в кроватке).* Да, давайте положим Катеньку в кровать *(вместе с детьми кладет куклу в кровать).*
Воспитатель: Пока кукла спит, я предлагаю вам отправиться в прошлое. Подойдите ко мне ближе.
«Вокруг себя повернись,
В прошлом со мною окажись»
*Дети закрывают глаза, педагог в это время надевает платок и сарафан.*
Воспитатель: Ребята, давным-давно, в старые времена, младенца укачивали в подвешенной к потолку кроватке, которая называлась колыбель *(показывает картинку колыбели).* Колыбель – это не единственное название, ее также называли зыбка или люлька. Вместо одеяльца в кроватку клали соломенный матрасик или настеленную толстым слоем солому. Над колыбелью всегда была занавеска (или полог) из ситца или холста *(демонстрирует иллюстрации).*
Воспитатель: А как, вы думаете зачем нужен полог?
Дети: От мух, света.
Воспитатель: Полог защищал от мух, комаров, света. И даже от злых сил. В место игрушек в колыбель привязывали цветные лоскутки и деревянные ложки.
Когда мама укладывала спать малыша, она пела ему колыбельную песню. Петь нужно было до тех пор, пока малыш не уснёт.
*Игра-имитация*
Воспитатель: Сейчас, я спою вам ещё одну колыбельную песенку. А вы, дети, возьмите кукол-малышей в руки и ласково качайте их, баюкайте и пробуйте повторят за мной.
Ой люли, люли, люли,
Прилетели гуленьки.
Прилетели гуленьки,
Сели возле люленьки.
Они сели ворковать.
Нашу деточку качать.
Воспитатель: Ребята, колыбельные песни по характеру какие? *(ответы детей).*
Правильно, колыбельные песенки очень размеренные и медленные, поют их негромко. И в таких песнях много ласковых и нежных слов. А создал колыбельные песенки народ. Мама сочиняла и пела песенку дочке. Дочка передавала своей подружке, а подружка спела младшему братику. Так и сохранились колыбельные песни до наших дней.
Воспитатель: Я хочу вас познакомить ещё с одной колыбельной песенкой. Послушайте я вам её спою.
Сладко спи, младенец мой,
Глазки поскорей закрой
Баю-баю, птенчик спать!
Будет мать тебя качать.
Папа сон оберегать.
Воспитатель: Дети, вам понравилась песня? Какие красивые слова услышали? *(Ответы детей)*
3. Окончание занятия. Подведение итогов
Воспитатель: Ну, что же, нам пора возвращаться в детский сад.

«Вокруг себя повернитесь
В детском саду окажитесь»
Воспитатель: Смотрите, ребята, уже и кукла Катенька проснулась ото сна. Давайте расскажем ей, что мы делали на занятии, что нового узнали и какие песенки пели *(ответы детей).* Вам понравилось наше путешествие в прошлое? *(ответы детей).*

**Шакирова Гульнара Назиповна**
**МБДОУ «Арский детский сад№9»**
**Арского муниципального района РТ**

**«Бишек белән таныштыру"**
Кече яшьтәге балаларны халык көнкүреше белән таныштыру буенча шөгыль конспекты

**Максат**: Балаларны халык традицияләренә җәлеп итү. Халык авыз иҗаты әсәрләренә эмоциональ хис үстерү. Фольклор әсәрләрен көндәлек тормышта тиешле ситуацияләрдә куллану күнекмәләрен тәрбияләү.
**Бурычлар**:
- Балаларны халык көнкүреше предметы – бишек, аның кулланылышы һәм бизәлеше белән таныштыру.
- Бишек җырлары турында төшенчә бирү.
- Балаларның күзаллауларын киңәйтү, сүзлек запасын баету.
- Уңай эмоциональ реакция һәм балалар турында кайгырту теләге тудыру. Җиһазлар: бишек, бишек бизәлеше, чүпрәк курчак, уенчык әтәч, кечкенә чүпрәк курчаклар һәм балалар саны буенча бишекләр.
Шөгыль «Татар өе» мини - музеенда уза.

**Шөгыль барышы:**

Тәрбияче: Хәерле көн, балалар, узыгыз, оялмагыз. Сез миндә кунакта булганыгыз бармы? Минем йортымда нәрсә кызыклы? Әйдәгез, искә төшерик һәм сөйлик.
Тәрбияче балаларга йортның бизәлеше турында сораулар бирә.
Менә бу матур бизәлгән сандык. Мин анда төрле әйберләр саклыйм: кием, сөлгеләр.
Бу мич, анда токмачлы аш һәм ботка пешерелә. Мич өстендә тагын нәрсәдер бар.
Балалар,табышмакны тыңлагыз:
Йонлач, мыеклы,
Мичтә утыра,
“Мыр - мыр дия. Дөрес,песи.
- Ә бу өстәлдә нәрсә тора? Ул ялтырап тора, әйтерсең лә учак яна! Әйе,молодөы, дөрес. Бу самовар, аннан чәй эчәләр. Әйдәгез, без дә сезнең белән хуш исле чәй эчәбез.
Сюжетлы уен: “Чәй эчү". Ә хәзер уңайлырак урнашыгыз. Һәркем күрәме, һәркем ишетәме, барыгызга да урын җиттеме?
Колаклар, күзләр әзерме,
Мин сезгә әкият сөйләрмен.
Әминә исемле курчак яшәгән.
Тәрбияче курчакны күрсәтә. Менә ул, безнең Әминә, алма төсле кыз, алсу йөз, яңаклар, алма, җиләкле иреннәр, төймәле борын- Нинди матур! Әйе, Әминә кәефсезләнә. Аны яткыралар, ә ул йоклый алмый.
Әй, Әминә, елама, сиңа сохари сатып алам,
Әй.Әминә, елама, сиңа калач сатып алам.
- Әйдәгез, балалар, Әминәгә барыбыз бергә шаяртып сөйлик.
Балалар тәрбияче белән тагын бер тапкыр кабатлыйлар.
- Йокламый. Балалар,нәрсә эшләргәикән? Без аны ничек йоклатырга тиеш?

- Җырлыйбыз, җырлыйбыз. Тәрбияче кулларында курчак һәм ул җырлый: «ә-ә-ә»җырына селкетә.
Балаларга селкетергә тәкъдим итә.
- Йокламый. Тәрбияче әтәч булып сөйли:
-Ку-ку-ку! Кем елый? Кем йоклый алмый? Мин әтәч-йорт хуҗасы, биек утырам, йортны саклыйм, барысын да ишетәм.
Балалар әтәчкә нәрсә булганы турында сөйлиләр.
- Мин сезгә ничек ярдәм итәргә икәнен беләм. Карагыз, мин сезгә нәрсә китердем.
Әтәч балаларга бишек күрсәтә. Тәрбияче балаларга мөрәҗәгать итә.
-Карагыз, әтәч безгә нинди бишек алып килде. Бу кечкенә бишек түшәмгә беркетелә һәм селкенә. Бала анда ята һәм йоклый. Бу бишек дип атала. Карагыз, мамык мендәр, йомшак мендәр, җылы одеял бар, шуңа күрә безнең Әминәгә йомшак һәм җылы, һәм ул тиз йоклый.
Тәрбияче балалар белән сөйләшә:
-Бишеккә мамык йомшак ястыкка салабыз, җылы одеял белән каплыйбыз. Менә Әминәне йоклаттык, ә хәзер мин аңа бишек җырын җырлыйм. Тавышсыз, назлы итеп, ә сез игътибар белән тыңлагыз. Тәрбияче бишек җырын җырлый :
-Элли –бәү, элли бәү, син, эт, ыңгырашма, әтәч, кычкырма, безнең Әминәне уятма. Әминә нык йоклый, күзләрен яба.
- Хәзер барыбыз бергә җырлыйк, миңа ярдәм итегез.
-Безнең Әминә йоклап китте. Йокласын, зур үссен. Әйдәгез, минем сандыкта тагын нәрсә ятканын карыйк.
Тәрбияче балаларга кечкенә бишекләр һәм курчаклар тарата, балалар курчакларны селкетәләр һәм аларга бишек җырлары җырлыйлар. Ә хәзер, әйдәгез, бишекләребезне балаларга күрсәтик һәм алар белән уйныйк.
Балалар төркемгә китә.

**Вахитова Глюся Гаптельнуровна**
**МБДОУ «Детский сад №6 «Радуга» г. Кукмор»**
**Кукморского муниципального района РТ**

## Бишек – зур дөньяга ишек

**Максат:**
1. Балаларны халкыбызның йөрәк түреннән чыккан җәүһәрләре – бишек җырлары белән таныштыру;
2. Бишек җырларның эчтәлеген һәм тәрбияви үзенчәлекләрен ачыклау;
3. Әти - әнигә, әби-бабайларыбызга һәм моңлы бишек җырларына мәхәббәт тәрбияләү.

### Бәйрәм барышы

***Воспитатель:*** Добрый день, уважаемые родители! Сегодня наша с вами встреча посвящена такой замечательной теме, как « Колыбельная песенка». Каждый родитель, бабушка или дедушка обязательно напевает своим детишкам или внучатам колыбельную песенку перед сном.
**А.Б** Исәнмесез хөрмәтле кунаклар. Сезне кабаттан үзебезнең “Салават күпере” балалар бакчасында күрүебезгә бик шат. Бүгенге очрашуны без “Бишек – зур дөньяга ишек” дип атарга булдык.
Саклыйк буыннарга рухи хәзинәне,
Бишек җыры-күңел көзгесе.
Киләчәктә шәхес булыр өчен
Тәүге адым, яшәү өлгесе.
Хәзер сезнең игътибарыгызга бакчабыз балалары һәм тәрбиячеләре тарафыннан әзерләгән “Бишек – зур дөньяга ишек” дигән күренешне тәкъдим итәбез.
*Талгын гына бишек көе яңгырый, ана коляска белән чыга. Арттан алып баручы сөйли:*

**А.Б.**
Бала туды бүген җиргә,
Җиһанны нурга күмеп.
Барлык туганнар сөенде
Бишектә сабый күреп.
Гаиләгә шатлык булып, өмет һәм куанычлар өстәп дөньяга олы зат туды . Дөньяга яңа кеше туды! Ул үзенә бәхет даулап тәүге авазын салды. *(Бала елаган тавыш)*
Ана: И-и-и балакаем, нигә елыйсың һаман, әле яңа гына ашаттым да бит үзеңне, астыңда коры. Нәрсә булды соң сиңа? *(Колясканы тирбәтә)*.
*(Әби керә, кулында бишек)*
**Әби**: Исәнме, кызым. Исән-сау кайттыгызмы?
**Ана:** Әйдә, әни, рәхим ит, түрдән уз.
**Әби**: Күрим әле оныгымны,
Карап туймаслык бала.
Кызым, кияү котлыйм сезне
Күз тимәсен Сөбеханалла.
Кызым, безнең бәләкәч нигә елый соң, авырмыйдыр бит?
**Ана**: Белмим шул, әни. Үзем дә аптырадым инде.
**Әби**: Кая әле, карыйм әле, нәрсә булды икән сабыема. *(Коляскaның эчен тотып карый).* Ииии, бу арбада нинди бала йоклый алсын инде. Кая әле мин алып килгән тал бишек. *(Бишекне алып килә)* Кызым, менә бу бишекне әтиең сиңа дип үргән иде. Татар халкында элек-электән тал бишекне әтиләр үз куллары белән үреп, үзләренең йөрәк җылысын биреп ясаганнар. Ә матур чыбылдыкларны әниләр үзләре теккән. Ул чыбылдык сабыйны явыз көчләрдән, күзләрдән, салкыннардан саклаган. Хәзерге яшьләр гореф – гадәтләребезне бөтенләй онытып баралар. *(Баланы коляскадан алып бишеккә сала)*
Әле кайчан гына кызым, сине шушы тал бишеккә салып, бишек җыры җырлап йоклаткан идем.
*(Бишек җыры җырлый.)*
Кояш ятты бишегенә,
Күзләрен йомды.
Кошлар да сайрамый инде,
Җилләр дә тынды.
Яфраклар да серләшмиләр,
Йоклады каен.
Без дә йоклыйк, бәү – бәү итик
Улым, улкаем.
Менә, бишек җырын ишетүгә улым да йокыга китте. Кызым, сорарга да онытып торам икән, кияү кайда соң, күренми?
**Ана**: И әни, эштә әле ул, һаман кайтып җитә алмый. Ярый әле миңа булышырга бәләкәчемнең абыйлары, апалары бар.
**Әби**: Кайда соң минем яраткан оныкларым? Балалар бакчасындадыр инде?
**Ана**: *(Тәрәзәдән карап)* Әнә, үзләре дә кайтып киләләр. Күрше Анна апага алып кайтырга кушкан идем.
*(Балалар белән Анна апа керә)*
**Анна**: Исәнмесез, здраствуйте мои дорогие соседи.
*(Балалар әбиләрен барып кочаклыйлар)*
**1 бала:** Исәнме, әбием.
**2 бала:** Әбием, сине сагынып беттем.
**3 бала:** Әбием, мин дә сине бик сагындым.
Әби: Исәнмесез, балакайларым мин дә сезне бик сагындым. *(Балаларның аркаларыннан сөя, кочаклый)* Исәнме Анна туганкаем.

**Анна**: Здраствуй, Фания. Давно мы с тобой не виделись. Я привела твоих внуков, и зашла заодно поздравить вас с рождением ребенка. *(Балага карый)* О какой богатырь у вас, тфу-тфу. Не плачет ли, хорошо спит и ест?
**Әби**: Ииии , плачет шул, плачет. Әле только, туктады. Бишеккә салып песенку спела.
**Анна**: Колыбельную песенку пела, что ли?
**Әби**: Әйе, бишек җыры җырладым да шундук уснул.
**Анна**: Молодец, Фания. Я тоже пою своей внучке колыбельную песенку. И моя сноха тоже поет колыбельную песню, когда укладывает дочку спать.
**4 бала:** Бабушка, бабушка, я тоже научилась пить песню своей сестренке. Можно, я спою колыбельную песенку?
**Анна**: Айда, внучка, спой. А мы тебя послушаем. *(Колыбельная песенка)*
*(Ишек шакыйлар, удмурт һәм марий хатын –кызлары балалары белән керәләр)*
**Мама удмуртка:** Зейч – буреч. Здраствуйте, можно к вам?
**Ана**: Заходите, заходите. *(Әнисенә)* Әни, иптәш кызларым да хәл белергә килгәннәр.
**Мама марийка:** Салам лейжо. Давно мы к вам в гости собирались. И дети хотели уведить малыша. Примите наш подарок. *(Дают подарки)* Пусть ваш сыночек растет здоровеньким и счатьливенким.
**Мама удмуртка:** Моя Настенька так хотела видеть твоего малыша, и даже выучила стихотворенние.
**Ана**: Ой, как я рада, мы послушаем тебя, с удовольствием.
*Стихотворение на удмуртском языке*
**Мама марийка:** Как у вас здесь интересно. Хорошо, что мы все здесь собрались. По марийским традициям у нас пологается встречать малыша в своих национальных костюмах веселыми песнями и танцами.
**Марийский танец**

**Әби:** Иии, минем оныклар да төшеп калганнардан түгел. Кызларым, улларым, әйдәгез сез дә татарча җырлап – биеп күрсәтегез әле.
**Кыз:** Дусларыбыз киткәнче,
Бала уянып җиткәнче
Кызык итик тик тормыйк,
Җырлы уеннар уйныйк.
**Зәңгәр чәчәк**
*(Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала, чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәлә)*
Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.
***(Туктап биеп торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йөри):***
Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр -
Мендәреңне сал әле.
*(Мендәр тоткан бала бер баланы сайлап ала һәм аңа кулын бирә, мендәрне идәнгә куеп әйләнәләр. Башкаларда култыклашып әйләнәләр.)*
**Ана**: Рәхмәт, сезгә, дусларым – күршеләрем, безне зурлап килгәнегез өчен. Рәхмәт сезгә, балалар, сез килгәч бигрәк тә күңелле булды.
**Анна апа:** Да, очень интересно было у вас. Уважаемые мамы, воспитывая ребенка в любви и заботе, обратите особое внимание колыбельным песням. Пойте колыбельные как можете, на любой мотив, удобный для вас. Главное – с любовью. Пусть ваши дети тоже

выучат колыбельные песни и будут петь своим куклам, это им пригодится , когда они сами будут папами и мамами.
**Мама марийка:** Мы все живем в мире и согласии и приобщаем детей к народной культуре и традициям. Ведь не зря у марийцев говорят: Калыкам йоратет гын, калыкат тыйым йората. (Что любит народ, и народ тебя полюбит.)
**Мама удмуртка:** И у удмуртов тоже говорят: Калыклэсь кужымзэ уд вордымы. (народную сиду не преодолеешь).
**Әби**: Бишек җырлары-безнең киләчәгебезгә нигез сала. Балаларны шул могҗизалы җырлардан мәхрүм итмәсәк иде! Җырларыбыз учагы сүнмәсен, алга таба дәвам итсен!

**А.Б.** Хөрмәтле кунаклар, хәзер инде бәйрәмебезнең конкурс өлешенә күчәбез. Бүгенге бәйгедә катнашучы иң сөйкемле, уңган, булган кызларыбыз белән таныштырып үтик.
1.
2.
3.
4.
5.
**Вед**. Посмотрите внимательно на героинь торжества. Они поражают своей красотой, девичьим очарованием, искренней улыбкой. Будем надеяться, что каждая из них порадует нас своей эрудицией, артистичностью, оригинальностью решений самых трудных задач. Пожелаем им успеха!
Ну, а какой же конкурс без жюри!
Жюри – это классно,
жюри – это сила,
Жюрить справедливо могут не все!
Кто же какое званье получит?
Об этом жюри нам скажет в конце.
А оценивать мастерство наших конкурсанток будет компетентное жюри в составе……….
Оценивается каждый конкурс по пятибалльной системе.
Вед: Внимание! Внимание! Начинаем первое испытание – “Здраствуйте! Это я” - “Исәнмесез! Бу мин”
Сейчас мы увидим, как обаятельны наши девочки, как они умеют говорить. Мы узнаем, какой у них характер и чем они интересуются
Каждая из девочек нам расскажет в интересной форме о себе, о своих интересах и увлечениях.
1 “Здраствуйте! Это я” - “Исәнмесез! Бу мин”
Вед: Дорогие гости, для вас дети подготовительной группы исполняют удмуртский танец «Танец с платочками»
А.Б. Һәрбер бала кечкенәдән үк файдалы һәм зыянлы ризыкларны дөрес итеп аера белергә тиеш. Сәләмәтлеккә зыян салучы ризыклар безне ал, аша дип торсаларда, бала алардан баш тарта белергә тиеш. Карыйк әле, безнең кызлар бу эшне дөрес итеп башкара алырлармы икән. Кызлар, өстәлдәге ризыкларның кечкенә балага файдалыларын яшел кәрзингә салырга, ә зыянлыларын кызыл кәрзингә салырга кирәк. Ягез, уңышлар сезгә.
2. Файдалы ризыкларны сайлау.
А.Б. Сезнең игътибарыгызга зурлар төркеме балалары башкаруында бию ”Авыл кичләре”
Вед: Одним из самых удобных видов кроваток для новорождённых является колыбель. Недолгий срок использования компенсируется невероятным удобством в первые месяцы жизни. Существуют очень много разновидностей колыбели для новорожденных:
классические кроватки-колыбели;
передвижные колыбели-люльки; приставные к родительской кровати;

анатомические колыбели-коконы; подвесные колыбели-гамаки; трансформеры и другие. А сейчас мы предлагаем вашему вниманию конкурс “Пазлы”. Вам необходимо собрать в единое целое различные виды колыбелек.
3. Пазллардан бишек җыю .
Вед: Встречайте детей средней группы, со своими чудесными балалайками.
Танец “Чудо балалайка”
А.Б. Халкыбызда бишек җырлары, борын заманнардан ук барлыкка килгән. Балалар сөйләшә белмәсә дә , шул авазларны тыңлап яткан, шулай рәхәтләнеп йоклап киткән.
Ана теле сабый күңеленә җыр булып керә. Бишек тибрәткәндә ана үзенең газизенә әйтәсе сүзләрен җыр- моңга төреп җиткерә. Бала чактан ук әни балаларын бишек җырлары белән юата, тынычл андыра. Ана,бигрәк тә, кыз балалага кечкенәдән үрнәк булып тора, үзенен белгәнен кызына да өйрәтә. Бәйгедә катнашучы кызларны да әниләре бишек җыры җырларга өйрәткән дип ышанабыз. Кызлар, сүзне сезгә бирәбез.
4. Бишек җыры җырлау.
Вед. Наши девочки решили
В дочки-матери сыграть.
А теперь мы им предложим –
Крошку-дочку спеленать.
Каждая участница должна быстро запеленать куклу. Учитывается скорость выполнения и качество пеленания.
**5. "Пеленание куклы"**
Вед: На этом наш конкурс подошел к концу. И пока наше жюри подводит итог, я вам предлагаю послушать песню в исполнении **подготовительной группы “А я колышки тишу”**
А.б. Йомгаклау өчен сүзне хөкемдарларга бирәбез.
Бүләкләү

**Зиганшина Чулпан Фирдинандовна**
**Хисамутдинова Гульназ Анисовна**
**МБДОУ «Арский детский сад №8»**
**Арского муниципального района РТ**

## Моңлы бишек җыры

*(Өй күренеше, капка төбе)*
*(Балалар музыка астында керәләр тезелешеп)*
-Балалар менә без әбигә килеп життек, ишеге бикле икән әбинең, әйдәгез шакып карыйк эле (*ишек шакыйлар- Ишетми*)
- Ишетми әби, бик каты коймак пешерә ахры, әйдәгез ул чыкканчы бер уйнап алабыз.
- Уйныйбызмы балалар? (*Балалар уйныйбыз дилэр)*
- Без сезнең белән «Ачык авыз» уенын уйныйбыз (*түгәрәккә басабыз парлашып, беребез артына беребез, <u>музыка уйный</u> арттагы кызлар уртага чыгып биилэр, алдагы малайлар урыннарында басып кул чабалар, <u>музыка туктый</u> балалар урыннарына барып басалар. Бер бала парсыз кала, ул уртага килеп баса –сорыйбыз бу кем диеп, балалар –ачык авыз диеп кычкыралар).*
(Ишек артыннан эби чыга)
ӘБИ - Исәнмесез, балалар ишетмичә дә торам икән сезне.
БАЛАЛАР – Исәнме әби, без сиңа кунакка килдек.
ӘБИ - Бик әйбәт, мин сезне күптән көтэм инде. Әйдәгез түрдән узыгыз балалар. Сезне сыйлыйм дип төрле-төрле тәмле ризыклар пешереп куйдым балаларым. Әйдәгез өстәл

артына утырыгыз. Менә шулай (өстәл артына утыралар). Өчпочмаклар, бәлешләр, өлешен дә пешердем балалар. Ә коймакларын авыз итегезче.

Фәридә: Коймагы да коймагы,
Агып тора каймагы.
Табада пешеп тора,
Табынга тешеп тора.
Кайнар! – яланкул тотма,
Тәмле! – телеңне йотма.
Син телең йотсаң, Нәбирә,
Кем рәхмәт әйтер әбигә?

ӘБИ: И рәхмәт инде кызым, матур сүзеңә. Бигрәкләр дә мактап җибәрдең үземне. Ашап утырыгыз балалар. Әйдәгез бер дога кылыйк та.

БАЛАЛАР: Рәхмәт әби.

ИСЛАМ: Өчпочмакарын тәмле булган әби.

АЙЗИЛӘ: Бәлешең телеңне йотарлык булган.

ТӘРБИЯЧЕ: Инде бераз ашап эчеп алдык, әллә бераз уйнап алабызмы әллә?

БАЛАЛАР: Әйдәгез, уйныйбыз.

*( “Ак калач” уены. Балалар түгәрәккә тезеп басалар, Сәйдә уртада, Ак калач җырын җырлыйлар. Аннан түгәрәк эченә Айзилә керә, кабаттан җырлыйлар.)*

ӘБИ: Балалар сезнең теге юлы килгәндә курчакларыгыз калган иде бездә. Әйдәгез карап карыйк әле, бәбиләрегез сагынгандыр инде сезне. *( Балалар керәләр, курчакларын кулларына алып идәнгә утыралар)*

СӘЙДӘ: Әлли-бәлли бәү итә,
Бәби йокыга китә.
Бәби йокыга киткәч,
Әнисе кайтып җитә.

ТӘРБИЯЧЕ: И-и балалар, сабыйга ана назы, йөрәк җылысы кергән бишек җыры кирәк ул. Әби-бабаларыбыз элек-электән әйтеп килгәннәр, бишек җыры тыңлап үскән баланың теле иртә ачыла, сәләтле, акыллы бала булып үсә.

ӘБИ: Ул аны тынычландыра, йоклата. Сиңа да кызым нәни чагыңда бишек җырларын җырлый идем. Кызлар әйдәгез без дә бәбиләребезне алып йоклатыйк әле. Утырыгыз минем янга. *(Килеп тезелешеп утыралар)*

ТӘРБИЯЧЕ: Әби сезнең яш чакта, балаларны бишек җырлары көләп йоклатканнар. Әйдә син дә безгә бер бишек җыры җырлап күрсәт әле?

*(Бишек җыры)*

ӘБИ: Җырлармын балакайларым, әйдәгез матур итеп утырыйк, сез тыңлагыз..

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,

Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!
ТӘРБИЯЧЕ: Әби бик зур рәхмәт матур җырларың өчен, сый-хөрмәтләрең өчен. Ә Безгә инде бакчага кайтырга да вакыт җитте. Әйдәгез балалар, әбигә рәхмәт әйтеп, кайтыйк.
*(Музыка астына чыгып китәләр)*

**Нигметзянова Лилия Гаптелахатовна**
**МБДОУ «Апазовский детский сад»**
**Арского муниципального района РТ**

## Тынлап бишек моннарын

**Максат:**
1. Балаларны халкыбызның йөрәк түреннән чыккан җәүһәрләре – бишек җырлары белән таныштыру;
2. Бишек җырларның эчтәлеген һәм тәрбияви үзенчәлекләрен ачыклау;
3. Әти - әнигә, әби-бабайларыбызга һәм моңлы бишек җырларына мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** өй күренеше: бишек, курчак, чүпләмле сөлге, мендәр һәм башка урын – җир; бишек – арба рәсемнәре, ноутбук.

**Материал:** “Бишек җырлары.

**Кичә барышы:**

(***Сәхнәнең почмагында өй күренеше. Бишек эленгән.***

**Тәрбияче :**Исәнмесез, кадерле балалар! Безнең бүгенге кичәбез кунаклар белән ямьләнер. Әнә, карагыз, күпме кунак килгән безгә.Ә хәзер **“Тынлап бишек моннарынны”**дип аталган кичәбезне башлап җибәрәбез.

Безнең бүгенге кичәбез бишек җырларына багышлана.Гаиләгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, бала дөньяга килә.

Әлбәттә, куаныч белән бергә, мәшәкатьләр дә өстәлә. Бәбине гел карап, тәрбияләп үстерәсе була. Ул борчыла да,шатлана да, елап та ала. Менә шул чакта әниләребез бишек җырларын көйләп – җырлап йоклаталар, юаталар. (Көй уйнала “Бишек җыры” ишетелә.

Әлли-бәлли итәргә
Ал бишеге бар аның,
Алдына алып йоклатырга
Үз әбкәсе бар аның.
Ал бишеге бар аның,
Гөл бишеге бар аның.
Өзгәләнеп сөяргә
Үз әнкәсе бар аның.
Әлли-бәлли бәү итә
Кызым йокыга китә.
Кызым йокыга киткәч
Әнисе дә ял итә.

**Тәрбияче:**

Бишек җырлары халык җырлары белән бергә яшәп килә.Халкыбызда бишек җырлары борын-борын заманнарда ук барлыкка килгән. Аларны халык үзе уйлап тапкан, буыннан буынга күчеп, алар безгә килеп җиткәннәр. Балалар сөйләшә белмәсә дә, шул авазларны тыңлап яткан, шулай рәхәтләнеп йоклап киткән. Ана теле сабый күңеленә җыр булып керә. Бишек тирбәткәндә ана үзенең газизенә әйтәсе сүзләрен җыр-моңга төреп җиткерә. Бишек җырлары төрле җирләрдә яңгыраган. Бүген без дә кечкенә вакытта җырланган бишек җырларын искә төшерербез.

**Тәрбияче :**Бишекне турында сөйләшеп алыйк әле. Кечкенәләрне кая салып тибрәткәннәр соң? Кайда йоклатканнар?
**Балалар :** Бишектә селкетеп.
**Тәрбияче:** Бик дөрес балалар? (тәрбияче сиртмәле бишек турында сөйләп аңлата). Бишек нәрсәдән ясала? Бишекне миләш агачыннан ясарга тырышканнар, чөнки ул сыгылмалы агач, сынмаган.Әле аның шундый ырымы да булган: бишекне җимешләре күп булган агачтан ясарга кушканнар.Күбрәк балалар тусын өчен, бишекне тал агачыннан да үргәннәр.Әлеге бишек өй түренә эленгән.Аларга әнкәйләрнең моңнары сеңгән, теләкләре уралган. Бишек җырлары, бишек тирбәтеп, газиз баланы йоклатканда җырланган.
Сабый бишектә ята. Бишек электән ук табигый материаллардан хәзерләнгән. Ягы-ягы белән тал чыбыктан үрелгәннәре дә, такта кисәкләрен бизәкләп ясаганнарын да очратырга мөмкин. Бишекне дүрт тактадан рамка кебек озынча итеп эшлиләр . Аның төбенә капчык чүпрәген тегеп куялар. Бишек сиртмә ярдәмендә ыргакка эләгә һәм тушәмгә ныклы итеп беркетелә. Бишекне әнисенең караваты янына асып куялар. Бала бишеген өйнең матчасына беркетергә рөхсәт ителмәгән, халыкта алай эшләү баланы саташтыра дигән фикер яшәгән.
**Тәрбияче: Ә** сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы балалар?
**Балалар :** Юк, ә нәрсә сон ул чыбылдык?
**Тәрбияче:**
Чыбылдык ни өчен кирәк булган икән соң?
Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән. һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Бәби рәхәтләнеп йоклый. Безнең бәбиебез дә тынычлап йокласын**.** Бишек җырлары бишек янына утырып та, баланы кулга тоткан килеш тә башкарыла. Әлеге җырлар аша сабый тәүге мәртәбә матурлык, ананың йөрәк җылысы, ата-ана мәхәббәте, үз халкының рухы, аһәңле теле белән, туган йорт, туган туфрак төшенчәләре белән очраша. Элек балаларны бишектә генә түгел, ә мендәргә салып та йоклатканнар.
**( *Т.Миңнуллинның “Тал бишек” җыры яңгырый* .**
Сеңгәндер ул талбишеккә
Әнкәмнең моңнары да
Шулайдыр шул, талбишекнең
Юк шуңа тынганы да.
Бишеге дә үрелгән шул
Сөндә үскән таллардан-
Җырчы таллар, елак таллар...
Моңнар тама алардан.
Ул талларга ал таңнарда
Сандугачлар кунгандыр.
Кунып кына калмагандыр,
Оя корган булгандыр.
И тирбәлә өй түрендә
Талбишек талгын гына...
Үрсәгез бишек , алыгыз
Безнең як талын гына.
Бишек ничек җырламасын,
Сөн талларыннан үр дә!
Талбишектә үстем мин дә-
Сизелмимени бер дә?!
**Тәрбияче :**Ә менә бишекләрне бүген очратып буламы соң? Күргәнегез бармы?
**Балалар :** Безнен бакча музеенда бар.
**Тәрбияче :** Әйе, балалар безнен бакчабызнын музеенда саклана эле ул бишек.

Бишекләр инде өйләрдә юк диярлек, аларны заманча бишек –коляскалар алыштырды. Ә бит асылмалы бишек бик тә уңайлы булган. Карагыз әле: бишекне аяк белән дә тирбәтеп була, кул эшләре эшләп бәйләгәннәр, чиккәннәр, теккәннәр, ямаганнар, әниләр шулай итеп бар эшкә дә өлгергәннәр.Баланы йоклатканда әниләр бишек җыры белән йоклатканнар.Әйдәгез без дә курчагыбызны бишек җыры җырлап йоклатып карыйк . Бүген без дә кечкенә вакытта җырланган бишек җырларын искә төшерербез.Менә сез кечкенә вакытта сезне дә әниләрегез бишек җырлары белән йоклатканнардыр.
**Тәрбияче :**Әйдәле, Ясминә син курчакны бишеккә салып тирбәт эле.
Безнең бәбиебез дә тынычлап, рәхәтләнеп йокласын.**(** бишек җыры яңгырый.)
**Әлли-бәлли, былбылым**
Г. Афзал шигыре. Р. Әхъярова көе.
Җилләр дә тынган инде,
Күлләрдә томан инде,
Син дә йокла, күз нурым,
Әлли-бәлли, былбылым.
Әлли-бәлли, әлли-бәлли,
Әлли-бәлли, былбылым!
Күк тулы йолдыз гына,
Ай йөри ялгыз гына,
Син дә йокла, йолдызым,
Әлли-бәлли, былбылым.
Әлли-бәлли, әлли-бәлли,
Әлли-бәлли, былбылым!
Бал - шикәрдән тәмлесең,
Күр төшеңнең тәмлесен,
Ак көмештәй ай нурым,
Әлли-бәлли, былбылым.
Әлли-бәлли, әлли-бәлли,
Әлли-бәлли, былбылым!
**Тәрбияче** : Балалар, ошадымы сезгә бу җыр? Шундый моңлы җырдан соң, бала тирбәлеп йокыга китәрме?
**Балалар:** Әйе рәхәтләнеп изрәп йоклар сабыйебыз.
Әйе, әниләребезгә безне төн йокыларын калдырып, безгә назлы сүзләр әйтеп, җырлап юатканнары өчен мең – мең рәхмәт әйтик.
**Балалар:** Минем әбием безне уятканда менә мондый сүзләр әйтә:
Алтын, алтын, алтыным
Минем йөрәк ялкыным.
Уян, бәбкәм, күз нурым,
Кояш булып балкырмын.
**Балалар**: Ә мин "Үс -үс" иттерү сүзләрен беләм. Аны миңа әнием өйрәтте.
Үс, үс, улым, үс әйдә,
Дөнья бик киң, сыярсың.
Аягың җиргә терәрсең.
Башың күккә сузарсың.
Бу җирләргә сыймасаң,
Галәмнәргә чыгарсын.
**Тәрбияче :** Балалар бу җырларның барын да ишеткәнегез бар идеме соң? Хәзер бишек җырын еш ишетергә буламы, беләләрме аны кешеләр? Кирәкме соң алар?
**-** Әйе, хәзер бишек җырлары сирәк ишетелә шул. Ә аларны өйрәнәсе иде, башкаларга да өйрәтәсе иде.
***"Бишек җыры"*** яңгырый. ( Татар халык җыры. Габдулла Тукай сүзләре).
Әлли-бәлли итәр бу,

Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.
Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сина теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.
Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!

**Тэрбияче :** Ни сәбәпле бишек көенә бала изрәп йоклый?
Әби-бабаларыбыз бишек җырларын баланы тынычландыру, йокыга талдыру чарасы итеп кулланганнар .Бишек җырлары ана белән бала икәүдән-икәү генә калган вакытта башкарыла.Ана бу вакытта күңеле белән баланың рухи дөньясына якынаерга, уй-фикерләрен нәниләр кабул итәрлек итеп, гади итеп әйтергә омтыла. Бишек җырларын тыңлап үскән балалар игелекле булалар.Бишек җырларында нинди генә йомшак, матур сүзләр юк! Бу җырларда Әниләребезнең йөрәк җылылыгын, иркәләвен, сөюен,назлавын тоясың.

Ак дөньяны сиңа бүләк иттем,
Ак биләүгә сине биләдем.
Ак биләүгә сине биләдем дә,
Ак бәхетләр генә теләдем.

Бала-ул алтын җимеш, бала-ул йөрәк парәсе. Һәрбер әти -әни үз баласын шулай кадерләп кенә үстерә, кеше итәргә тырыша; гомерен,бөтен тормышын баласына багышлый.Әйдәгез, кичәбез ахырында әниләребезгә кояштай озын гомер телик, аларны кадерләп саклыйк, рәнҗетмик.

Әни – җирдә иң газиз, якын кеше. Ул сине тудырган, көйләп бишектә тирбәткән, синең беренче елмаюыңны, тәпи атлап китүеңне күреп шатланган, туган телен, халык моңнарын яратырга өйрәткән. Без үзебезнең тормышыбызны алардан башка күз алдына да китерә алмыйбыз. Алар – безнең дөньябызның яме.

Әниләр һәм бишек җырлары. Бу ике сүз бер-берсенә бик тыгыз бәйләнгән. Әниләрдән башка бишек җырын, бишек җырларыннан башка әниләрне күз алдына китереп булмый.Чөнки аларда тормыш чишмәсенең башы, яшәү чыганагы.

**Тэрбияче :** Рәхмәт сезгә, кадерле балалар! Менә мин сезне киләчәктә дә тату гаиләләрдә яшәсеннәр, өлкәннәрне хөрмәт итсеннәр, бишек җырларының моңы гомер буе озата барсын иде дигән теләктә калам.

Рәхмәт сезгә, кадерле кунаклар! Әле үзебез әниләр, әбиләр булгач та, кечкенәдән өйрәнгән бишек җырларыбызны онытмасак иде. Шуңа күрә, балаларга беренче елларында ук бишек җырларын көйләгез, ул баланың хәтеренә уңай тәэсир итә.

Буш вакытларыгызда, ял көннәрендә, эшләгәндә, бала йоклатканда бишек җырларын, халык җырларын искә төшерегез, үзегез белгән җырларны балаларыгызга өйрәтегез.

Бала-ул алтын җимеш, бала-ул йөрәк парәсе. Һәрбер әти -әни үз баласын шулай кадерләп кенә үстерә, кеше итәргә тырыша; гомерен,бөтен тормышын баласына багышлый.Әйдәгез, кичәбез ахырында әниләребезгә кояштай озын гомер

телик,аларны   кадерлик, хөрмәт  итик, яратыйк!

Аяз булсын  иртәләр!
Хөрмәтле кунаклар, безнең  кичәбез  тәмам,
игътибарыгыз өчен зур рәхмәт!

.

**Шаймарданова Гулфания**
**МБДОУ “Детский сад с. Янцобино”**
**Кукморского  муниципального района РТ**

## Исем кушу йоласы

*(Татар халкының гореф- гадәтләрен саклауга багышланган чара.)*

**Максатлар**: сәнгать әсәрләренең төп кыйммәтен,әһәмиятен һәм мәгънәсен аңлауга, кабул итүгә алшартлар булдыру;
балада үз халкына, гореф-гадәтләренә, йолаларына һәм мәдәниятенә карата уңай хисләр, мөнәсәбәтләр формалаштыру.
**Бурычлар**:
Балаларны исем кушу йоласы белән таныштыру.
Балада татар халкының гореф- гадәтләренә кызыксыну уяту.
Милләт тойгысы һәм милли горурлык хисе тәрбияләү.
Буыннар бәйләнеше, исемнәр, аларның килеп чыгышы, мәгънәсе турында күзаллауларын тирәнәйтү;
Гаиләң белән горурлану хисләре, өлкәннәргә ихтирам, хөрмәт тәрбияләү;
**Җиһазлау**: компьютер, экран, өй күренешенә атрибутлар,бишек, мендәр,бал һәм май салынган савытлар, күчтәнәчләр.
**Алдан башкарылган эш:** татар халык уеннары уйнау, татар халык әкиятләре тыңлау һәм карау, әңгәмәләр оештыру, мәкаль һәм әйтемнәр өйрәнү, татар исемнәренең мәгънәсен ачыклау.

### Бәйрәм барышы:

*Татар өе күренеше. Уртада бишек эленеп тора. Салмак кына музыка уйный.*
Алып баручы:
Әссәләмәгаләйкүм,-  диеп башлыйм әле,
Танышу бит шулай башлана.
Сезнең белән очрашканга, дуслар,
Күңелкәем шундый шатлана!
Исәнмесез хөрмәтле әти - әниләр, кадерле балалар килгән кунаклар! Бүген без сезгә татар гаиләсендә уза торган йолаларның берсе - Исем кушу йоласын күрсәтербез.
“Кыз бала исеме йолдыз балкышына охшасын, назлы гөлчәчәктәй нәфис булсын. Ир-ат исеме кылычлар чыңлавын хәтерләтсен, аның мәгънәсендә гакыл гәүдәләнсен»,- дип язган Рәсүл Гамзатов.
Яхшы исем кыйммәт барсыннан да,
Аннан тугры дусны күрмисең;
Безнең хакта мәңге ядкарь саклап,
Картаймыйча яши һәр исем. (Гамзат Цадаца)

Әйдәгез әле өй эченә күз салыйк.
*Бишек янында баланың әти – әнисе, баланы тирбәтәләр.  Ак әби утырып тора. Бишек янына килеп сүз башлый:*
Йокла, йокла, үскәнем,

Дәү үсәрсең йокласаң.
Онытмассың телеңне
Бишек җырын тыңласаң.
Ак әби: Бүген бездә зур шатлык. Дөньяга сабый туды. Өйдә гаиләгә яңа ямь, юаныч, бәхет өстәлде. Бәхетле булып, алтын канатлы булып үссен сабыебыз. Котлы булсын, бәби ашы, котлы булсын!
- Бүген без кунаклар җыябыз. Кая соң әле үзләре, күренмиләр *(Кулын каш өстенә куеп карый).* Киләләр икән киләләр. Әниләр үз балаларын җитәкләп бәби бишеге янына киләләр, әни кешеләр *кулларына мич ашлары (бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, чәк- чәк һ.б. )* тотып килә, ә балалар бәбинең матрас астына тимер акча куя котлап. *Балалар кулларын биреп Ак әби һәм баланың әти - әнисе белән күрешәләр.*
Алып баручы: Әниләребез күчтәнәчләр белән килгәннәр.
Ак әби: Рәхмәт балакайларым. Бик зурлап килгәнсез. Түрдән узыгыз, әйдә.
*Балалар һәм әниләр ике якка капма- каршы тезелеп утыралар.*
Алып баручы: Безнең балалар бәбине котлап матур шигырьләр өйрәнделәр.
Зинира:
Үчти үчти, үчтеки
Бәби бигрәк кечтеки
Үсәр әле зур булып
Бигрәк матур кыз булып.
Мәрьям:
Минем сеңлем дәү кебек,
Бакчадагы гөл кебек.
Ике күзе янып тора,
Кара бөрлегән кебек.
Без тагын баланы юындырганда әйтә торган юаткыч беләбез. Сөйлибезме?
Каюм:
Бәби юына суда.
Мунчала, сабын кулда.
Юа-юа юылган –
Сабын суда юк булган.
Ильяс:
Чулпан йолдыз таңгача
Бишегеңне тирбәтер,
Фәрештәләр, җыелып,
Тел ачкычы өйрәтер.
Ак әби: Рәхмәт балакайлар. Менә булдырасыз.
Алып баручы: Яшь бала туган гаиләгә мич ашлары пешереп алып килү – күркәм гадәт. Менә шундый тәмле ризыклар кебек әнисенең дә, әтисенең дә телләре татлы булсын.
Алып баручы: Балалар әниләрегез татар халкынын милли ризыкларын пешереп алып килгәннәр. Без аларны беләбез. Балалар, әйдәгез, табышмаклардан милли ризыкларыбызның исемнәрен табыйк:

Йомырка белән онны
Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар.
Балалар: Өчпочмак.

Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә.
Эчем тулган тәмле ит,

Май һәм бәрәңге белән.
Балалар: Бәлеш.

Вак-вак кына итеп кисеп,
Өяләр аны таудай!
Чак-чак кына алып, өзеп
Аша, дустым, син шулай.
Балалар: Чәк-чәк

Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың.
Ул нәрсә?
Балалар: Коймак.

А.Б. – бик дөрес балалар.
Бала елаган тавыш ишетелә. Әни сабыен кулына ала, баланы юатып шигырь сөйли.
Бишек җыры. (Г. Тукай шигыре, татар халык көе)
Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу,
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла, кызым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым,
Кичтән йокың кала да,
Еглап үтә көндезең.
Ана: Бу безнең кызыбыз . Бүген аның бәйрәме- Бәби ашы. Кара әле кызым, күпме кунак сине котларга килгән. (Бәбине яңадан бишеккә салып тирбәтә)
Алып баручы: Бала тугач, күңелле мәшәкатьләр башлана. Аның беренчесе – исем кушу. Аңа нинди исем бирергә. Бу сорау ата-ананы, туганнарны борчый, чөнки исем кешегә бер генә тапкыр бирелә.
Алып баручы: Һәр кешегә исеме туган тел кебек якын, газиз, кадерле. Балага исем кушу – бик җаваплы вакыйга . Күркәм исем белән дәшү балага дога кебек уңай тәэсир итә. Шуңа да балага яхшы мәгънәле исем кушарга кирәк.
А.Б. – әбекәй, элек балаларга нинди исемнәр кушканнар соң?
Ак әби: Элек исемнәрне уйлап кушканнар. Кызларга күбрәк чәчәк исемнәре кушканнар, чәчәк кебек матур булсын дигәннәр, Бай булсын дип, Байбикә, Алтынбикә, Сөембикә исемнәрен кушканнар.
Алып баручы: Әбекәй, ә малайларга элек нинди исемнәр кушканнар соң?
Ак әби: Ә малайларга тимер кебек нык булсын өчен Тимерхан, Биктимер, Байбулат дип кушканнар.
Алып баручы: Ә без бу нәниебезгә нинди исем бирербез соң? Әйдәгез шобага салабыз (Озын таякка бер - бер атлы тотынып балалар исем сайлыйлар, иң соңыннан таяк башын бәбинең әнисе тота һәм Айсылу кушабыз дип әйтә)
*Кечкенә бала елаган тавыш ишетелә. Әнисе бәбине бишектән алып өстәлгә мендәр өстенә куя, мулла исем куша.*
Алып баручы: Балалар без дә Корьән сүрәләре беләбез бит, әйдәгез әле Айсылуның иманлы, тәүфыйклы булуын теләп Корьән укыйк.
Ильяс “Фәтихә” сүрәсен укый.
А.Б. – Сөбханаллаһ булдырдың Ильяс, әйдәгез балалар бергәләп укыйбыз хәзер “Фәтихә” сүрәсен.
Каюм “Кәүсәр” сүрәсен укый.

А.Б. – Сөбханаллаһ булдырдың Каюм, әйдәгез балалар бергәләп укыйбыз хәзер “Кәүсәр” сүрәсен.
Муса  “КульһуАллаһ” сүрәсен укый.
А.Б. – Сөбханаллаһ булдырдың Муса, әйдәгез балалар бергәләп укыйбыз хәзер “КульһуАллаһ” сүрәсен. Ә хәзер Аллаһны мактау сүзләрен әйтәбез. Балалар бармакларын бөгеп 10 ар тапкыр “Сөбханаллаһ”, “Әлхәмдүлилләһ”, “Аллаһу әкбәр”, “Әстәгъфируллаһ” сүзләрен әйтәләр бергәләп.
Алып баручы: Ә хәзер балалар Айсылуның туган көнен котлап җырлыйбыз. *Балаларга уртага чыгып басып «Коймаклар» дигән җырлы- биюле уенны уйныйлар. Сүзләргә туры килгән хәрәкәтләр ясыйлар.*
Җырлы- биюле уен «Коймаклар»
Айсылуның туган көнендә
Без чакырдык кунаклар.
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.
Коймакларга карасаң,
Менә шулай күпергән,
Менә шулай җәелгән.
Менә шулай кысылган.
Коймагыңны майлап ал,
Теләгәнеңне сайлап ал!
Алып баручы: Балалар, ә хәзер кечкенә Айсылуга матур теләкләр әйтик.
Балалар: Бәхетле бул!
– Әти- әниеңне тыңла!
– Батыр, көчле булып үсеп җит!
– Сау- сәламәт бул!
– Матур бул!
– Таза – сау бул!
Тигез канатлы бул!
Тәүфыйкълы бул!
Алып баручы:*(Әни кешегә карап)* Кызыгызга бик матур, мәгънәле исем куштыгыз. (Айсылу - Ай кебек матур, айдай чибәр).
Безнең балаларның да исемнәре бик матур. Алар да үз исемнәренең нәрсә аңлатканын беләләр.
*Балалар үз исемнәре турында сөйлиләр.*
Бәбигә исем кушу бәйрәме бишек җырын җырлау белән тәмамлана.

**Ихсанова Гульнара Рафисовна,**
**воспитатель по обучению татарского языка**
**МБДОУ “Детский сад комбинированного вида**
**№14 “Родничок” г.Азнакаево Азнакаевского**
**муниципального района РТ**

## Мәңгелек җыр- бишек җырыбыз

мәктәпкәчә әзерлек төркемдә күңел ачу чарасы

**Максат:**
Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары белән танышу, аларга кызыксыну уяту.
**Бурычлар:**
-Балаларның монологик һәм диалогик сөйләм телен үстерү.
-Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары белән танышуны дәвам итү.
Горурлану, хөрмәт итү хисен тәрбияләү.

-Бишек җырларын өйрәнү.
-Ата- аналар белән тыгыз элемтәдә булу, аларның сценарий куюда ярдәм итү.
**Җиһазлау:**
Бишек
Самавыр
Чиккән сөлгеләр
Татар халкының милли киемнәре ( балаларга)
Савыт-саба
Милли ризыклар (чәк-чәк, өчпочмак)
Курчак
Магнитофон
Пианино
сандык
**Алдан эшләнгән эш:**
“Бишек туе” темасына әңгәмә үткәрү.
Татар халкының башка төрле йолалары, гореф-гадәтләре белән таныштыру.
Халык авыз иҗатының “үчти-үчти” сикерткәндә, теләкләр, бала йоклатканда әйтелә торган шигырьләр өйрәнү.
Дәрдмәнднең “Бәллү” шигырен өйрәнү.
Татар халкының милли биюен өйрәнү.
**Катнашучылар:**
Әби
Бабай
2 кыз, 2 малай
Әти
Әни

**Чараның барышы**

Авыл өе. Өстәл янында бабай, әби һәм дүрт оныкчыклары. Әби чәй әзерли.
**Әби:** -Балалар, әйдәгез әле чәй эчеп алыйк.
Барысы да өстәл артына утыралар.Чәй эчәләр. Ишек шакыйлар.
Әти белән әни керә.
**Әти**:- Сөенче,сөенче
Безнең гаиләдә сөенче!
Дөньяга аваз салып
Бишенче бала туды!
**Әби, бабай**: - Зур шатлык белән килгәнсен, улым! Әйдәгез, әйдәгез узыгыз, балалар.
Әни баласын гаиләдәге бөтен кешегә күрсәтеп чыга. Һәрберсе теләк теләп чыга.
**Әни**:
Минем кызым дәү кебек,
Бакчадагы гөл кебек.
Ике күзе янып тора,
Кара бөрлегән кебек.
**1нче кызы:**
Әлли-бәлли бәү итә,
Сеңлем йокыга китә.
Сеңлем йокыга китқәч,
Әнисе кайтып җитә.
**Малай** :
Әлли бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Йокыларга киткәчтен.

Бик дәү булып үсәр бу.

**Әти** :

Әттә, әттә, әттәти,
Минем кызым бик тәти.
Минем кызым бик тәти дә,
Йөреп китәр ул тәпи.

**Бабай:**

Үсә-үсә бәбкәем,
Үсә-үсә зур була.
Кояш кебек сөйкемле,
Үзе сүзгә җор була.

**Балалар**:- Әти-әни без сезгә бүләк әзерләдек.
Бииләр.
Бала елый башлый.
Әни бишектә тибрәтә башлый. Бала һаман елый.
**Әби:** - И-и балалар, сабыйга ана назы, йөрәк җылысы кергән бишек җыры кирәк ул. Әби-бабаларыбыз элек-электән әйтеп килгәннәр, бишек җыры тыңлап үскән баланың теле иртә ачыла, сәләтле, акыллы бала булып үсә.Ул аны тынычландыра , йоклата.Сиңа да кызым нәни чагында бишек җырларын җырлый идем.
**Әни**: -Әни, чынлап та искә төште җырлаганнарың. Әйдә әле җырлап җибәрик.
Кыйгач кашым,
Асыл ташым!
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү бәү!
Хублар хубы,
Алма тубы,
Пешкән,тулгансың,
Бу чагында
Син тагын да
Чибәр булгансың!
Алмакаем,
Аппакаем,
Йоклаек икәү!
Йокла,иркә,
йокла бәбкә,
Бәүкәй, бәллү бәү.
Дәрдмәнднең "Бәллү" шигыре, Р.Әхъярова көе
**Әби**:- Ана назы –җирдә ул мәңгелек
**Бабай**:- Мәңгелек җыр- бишек җырыбыз.


**Сагитова Гульназ Фаннуровна**
**МБДОУ «Арский детский сад №1»**
**Арского муниципального района РТ**


**«Бишек җырлары» күңел ачу чарасы.**

Зурлар төркеме өчен

**Максат:**
Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары белән танышу, аларга кызыксыну уяту.
**Бурычлар:**
-Балаларның монологик һәм диалогик сөйләм телен үстерү.

-Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары белән танышуны дәвам итү.
Горурлану, хөрмәт итү хисен тәрбияләү.
-Бишек җырларын өйрәнү.
-Ата- аналар белән тыгыз элемтәдә булу, аларның сценарий куюда ярдәм итү.
**Җиһазлау:**
Бишек, самавыр, чиккән сөлгеләр
Татар халкының милли киемнәре ( балаларга)
Савыт-саба
Милли ризыклар (чәк-чәк, өчпочмак)
Курчак
Магнитофон
Пианино
сандык
**Алдан эшләнгән эш:**
“Бишек туе” темасына әңгәмә үткәрү.
Татар халкының башка төрле йолалары, гореф-гадәтләре белән таныштыру.
Халык авыз иҗатының “үчти-үчти” сикерткәндә, теләкләр, бала йоклатканда әйтелә торган шигырьләр өйрәнү.
Дәрдмәнднең “Бәллү” шигырен өйрәнү.
Татар халкының милли биюен өйрәнү.
**Катнашучылар:**
Әби
Бабай
2 кыз, 2 малай
Әти
Әни

**Чараның барышы.**

**Тәрбияче:** -Хәерле көн, балалар!
***Талгын гына җыр ишетелә:***
*Әлли-бәлли итәр бу*
*Мәдрәсәгә китәр бу;*
*Тырышып сабак укыгач,*
*Галим булып җитәр бу.*
*Йокла ,углым ,йом күзең,*
*Йом-йом күзең , йолдызым;*
*Кичтән йокың кала да,*
*Елап үтә көндезең.*
*Гыйззәтем син, кадрем син,*
*Минем йөрәк бәгърем син;*
*Куанычым, шатлыгым*
*Тик син минем, синсең, син!(Г.Тукай “Бишек җыры”)*
Тәрбияче: Ишетәсезме, нинди моңлы җыр ишетелә. Сезнең мондый җыр ишеткәнегез бармы?
Балалар: Бар.
Тәрбиче: Балалар, бу бишек җыры. Бишек жырлары, гадәттә, баланы бишектә тирбәтеп йоклатканда көйләнә. Бишек тирбәткәндә килеп чыккан әлеге җырларны бишек җырлары дип йөртә башлаганнар.
Бишек электән ук табигый материаллардан хәзерләнгән. Ягы-ягы тал чыбыктан үрелгәннәре да очрый, тар гына такта кисәкләрен бизәкләп ясаганнарын да очратырга мөмкин. Бишекне дүрт тактадан рамка кебек озынча итеп эшлиләр . Аның төбенә нык

тукыма тегеп куялар. Бишек сиртмә ярдәмендә ыргакка эләгә һәм түшәмгә ныклы итеп беркетелә (бишек күрсәтелә).
Балалар, сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы? Чыбылдык ул – бишек өстенә каплап куела торган тукыма. Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Бәби рәхәтләнеп йоклый. (чыбылдык күрсәтелә)
Бүген бер йортта зур сөенеч – бәби туган. Әйдәгез бергәләп карап китик әле шул мизгелләрне.

***Авыл өе. Өстәл янында бабай, әби һәм ике оныкчыклары. Алар чәй эчеп утыра.***

**Әти**: (ишектән килеп керә)
Сөенче,сөенче, балакайларым! Дөньяга аваз салып сезнең энегез туды!

**Әби, бабай**: - Зур шатлык белән килгәнсен, улым! Әйдәгез, әйдәгез узыгыз, балалар.

*Әни баласын гаиләдәге бөтен кешегә күрсәтеп чыга. Һәрберсе теләк теләп чыга.*

**Әни**:

Минем улым дәү кебек,
Урмандагы имән кебек.
Ике күзе янып тора,
Кара бөрлегән кебек.

**1нче кызы:**

Әлли-бәлли бәү итә,
Энем йокыга китә.
Энем йокыга киткәч,
Әнисе дә ял итә.

**Малай** :

Әлли бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Йокыларга киткәчтен.
Бик дәү булып үсәр бу.

**Әти** :

Әттә, әттә, әттәти,
Минем улым бик тәти.
Минем улым акыллы да,
Йөреп китәр ул тәпи.

**Бабай:**

Үсә-үсә бәбкәем,
Үсә-үсә зур була.
Кояш кебек сөйкемле,
Үзе сүзгә җор була.

**Балалар**:- Әти-әни без сезгә бүләк әзерләдек (*Биеләр).*

*Бала тавышка уянып елый башлый.*
*Әни бишектә тибрәтә башлый. Бала һаман елый.*

**Әби:** - И-и балалар, сабыйга ана назы, йөрәк җылысы кергән бишек җыры кирәк ул. Әби-бабаларыбыз элек-электән әйтеп килгәннәр, бишек җыры тыңлап үскән баланың теле иртә ачыла, сәләтле, акыллы бала булып үсә.Ул аны тынычландыра , йоклата.

**Әни**: Чынлап та истә минем бу җырлар. Әйдә әле җырлап җибәрик.

Кыйгач кашым,
Асыл ташым!
Йоклаек икәү!
Йокла, иркә,
Йокла, бәбкә,
Бәүкәй, бәллү бәү!

Дәрдмәнднең “Бәллү” шигыре, Р.Әхъярова көе

***Катнашучылар бергәләп бәби тотып чыгып китәләр.***

Тәрбияче: Ана  бишек җыры җырлаганда сабыена үзенең изге теләкләрен тели. Бала елаганда да, ана сабыйны бишек җыры көйләп юата. Бала җырны тыңлап изрәп йокыга киткә.
-Балалар, сезгә әниләрегез бишек җыры җырлыймы? ( балалар җырлап күрсәтәләр)
- Балалар, ишеттегезме, бишек җырында әнисе сабыена нинди матур сүзләр белән эндәшә?
-Дөрес, балалар, әни баласына бары тик матур, назлы сүзләр белән генә эндәшә: алсу алмам, бердәнберем, терәгем,  алтыным, бәхетем, күз нурым, бәхет йолдызым.
- Ә сезгә әниләрегез нинди ягымлы сүзләр әйтә соң? Әйдәгез, без моны белү өчен “Ягымлы сүзләр”уенын уйнап алабыз. Бишек җыры башлануга бер-беребезгә курчакны тапшырабыз. Көй туктагач, кемдә курчак кала, шул ягымлы сүз әйтә.
 -Балалар сез бүген нинди яңалыклар белдегез?
-Әти-әниегезгә, дусларыгызга нәрсәләр сөйләрсез?
-Сау булыгыз!

**Гилязеева Алия Василовна**
**Гарифуллина Гульназ Фидаратовна**
**МБДОУ «Арский детский сад №8»**
**Арский муниципальный район РТ**

## “Бишек җыры” бәйрәме

**Максат**:
1. Балаларны халкыбызның йөрәк түреннән чыккан  җәүһәрләре – бишек җырлары белән  таныштыру;
2. Бишек җырларның  эчтәлеген һәм тәрбияви үзенчәлекләрен ачыклау;
3. Әти - әнигә, әби-бабайларыбызга һәм моңлы бишек җырларына мәхәббәт тәрбияләү.
**Җиһазлар**: Өй күренеше, сәке, бишек, чигүле сөлгеләр, мендәр һәм урын җир, диван.

### Бәйрәм барышы

Татар халык җыры яңгырый.
Балалар залга керә, аларны Сания әби каршылый. Кулында курчак.
Әби: Исәнмесез, кадерле балалар. Әйдәгез, рәхим итегез, оялмагыз. Уңайлы итеп утырыгыз.
Мин Сания әбиегез булам, бу минем оныгым Сөмбел
1 бала Сөмбел диеп,матур исем
Кушты икән кем генә?
Сөмбел гөлдән өзелеп төшкән
Чәчәк кебек Сөмбел ул.
**2 нче  бала**
Әткәсенә, әнкәсенә
Ул-күз карасы кебек
Гөл арасында сайраган
Былбыл баласы кебек.
**3 нче бала**
Чәчәк кебек сөйкемле ул
Былбыл кебек моңлы ул.
Таң аткач та сүнми торган
Йолдыз кебек нурлы ул.

Без бүген оныгым Сөмбел белән бик күп эшләр эшләдек. Хәзер аңа йокларга вакыт. Сезнең килү әйбәт булды, миңа оныгымны йоклатырга булышырсыз.

**1 слайд (татар өе)**

Сөмбел кызымны кулда гына йоклатам һәм җырлыйм..
(Әтәч тавышы ишетелә)
Әби: Балалар, бу әтәчләр кызыма йокларга бирми. Нәрсә булган аларга, карагыз эле тәрәзәдән, сугышалар түгелме алар?

**2 слайд (әтәч, “Чукмар белән Тукмар” әкиятеннән өзек)**

Әби: әтәчләр сугышмасын өчен, әйдәгез, без аларны уйнатабыз.

**Флешмоб «Чеп- чеп чебиләрем”**

Әби: Мин Сөмбелне тагын йоклатып карыйм (кулында селкетә)
Барыбер йокламый бу кыз.

**3 слайд (ишегалды)**

Әби: Балалар, бәлки сез шигырь сөйләп карасыз.
1 бала
Үчти-үчти үчтеки, үсте китте кечтеки.
Үсте, үсте, зур булды, таза һәм матур булды,
Акыллы, зирәк булды,
һәркемгә кирәк булды. (Ренат Харис)
2 бала Йокла, курчак Йокла, курчак, нәни курчак,
Мин дә йоклыйм, ял итәм,
Йокласаң ял итәрсең.
Әлли-бәлли, бәү итәм. Әлли-бәлли итәрсең.
Йоклап туйгач, таза булып,
Таза булып, матур булып,
Матур булып, зур үсәм.
Курчагым, зур үсәрсең.
Әлли-бәлли, бәү-бәү. Әлли-бәлли, бәү-бәү,
Нәни курчак, тыныч ят (Гыйльмия Таһирова)
Әби: Болай да булмады әле, балалар. Бәлки песине чакырып карарбыз
Балалар: Пес- пес- пес
Песи керә.
Балалар:
Мияу – мияу мышнаган,
Мич башында кышлаган,
Бүген тычкан тотмаган,
Тотар иде – йоклаган.
Песи – песи поскан,
Ике күзен кыскан.,
Кысса безне тоталмый,
Тотар иде, җиталмый.

**Хәрәкәтле уен “Песи һәм тычканнар» татар халык уены**

Әби Сөмбелне кулында тирбәтә, бала йокламый.
Әби: балалар, бер биеп алыгыз булмаса.

**4 слайд ( «Маша һәм Аю” мультфильмнан видео)**

Флешмоб
Әби:
Менә гаиләгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, бала дөньяга килә. Әлбәттә, куаныч белән бергә, мәшәкатьләр дә өстәлә. Бәбине гел карап, тәрбияләп үстерәсе була. Ул борчыла да, елап та ала. Менә шул чакта әниләребез бишек җырларын көйләп, җырлап йоклаталар, юаталар. Халкыбызда бишек җырлары борын-борын заманнарда ук барлыкка

килгән.Балалар сөйләшә белмәсә дә, шул авазларны тыңлап яткан, шулай рәхәтләнеп йоклап сөйләшә .(Бала елаган тавыш ишетелә)
Баланы йоклатканда әниләр бишек җыры белән йоклатканнар.Әйдәгез без дә курчакларыбызны бишек җыры җырлап йоклатып карыйк . Бүген без дә кечкенә вакытта җырланган бишек җырларын искә төшерербез. Менә сез кечкенә вакытта сезне дә әниләрегез бишек җырлары белән йоклатканнардыр.
Бишек җыры җырлау(балалар үзләренең курчакларын тотып җырлыйлар)
Әби:Менә Сөмбел йоклап та китте,әйдәгез аны бишеккә салабыз (курчакны бишеккә куя)
Тәрбияче: Сабый бишектә ята. Бишек электән ук табигый материаллардан хәзерләнгән. Ягы-ягы белән тал чыбыктан үрелгәннәре да очрый, тар гына такта кисәкләрен бизәкләп ясаганнарын да очратырга мөмкин. Бишекне дүрт тактадан рамка кебек озынча итеп эшлиләр . Аның төбенә капчык чүпрәген тегеп куялар. Бишек сиртмә ярдәмендә ыргакка эләгә һәм тушәмгә ныклы итеп беркетелә. Бишекне әнисенең караваты янына асып куялар. Ә менә бишекләрне бүген очратып буламы соң?Бишекләр инде өйләрдә юк диярлек, аларны заманча бишек –коляскалар алыштырды.
Сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы? Чыбылдык ни өчен кирәк булган икән соң? Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Бәби рәхәтләнеп йоклый. Безнең бәбиебез дә тынычлап йокласын**.** Бишек җырлары бишек янына утырып та, баланы кулга тоткан килеш тә башкарыла. Әлеге җырлар аша сабый тәүге мәртәбә матурлык, ананың йөрәк җылысы, ата-ана мәхәббәте, үз халкының рухы, аһәңле теле белән, туган йорт, туган туфрак төшенчәләлре белән очраша. Элек балаларны бишектә генә түгел, ә мендәргә салып та йоклата идек.
Менә шулай, балалар, әниләрнең, әбиләрнең, дәү әниләрнең бишек җырлары – бала өчен иң беренче, иң ягымлы көй ул. Дөнья белән, табигать белән танышу туган тел аша, Тукай шигырьләре аша, бишек җырларыннан башлана.
Әби: Сөмбел йоклаган арада мин сезне пешергән күмәчләрем белән сыйлыйм.

**Галиәхмәтова Гөлүсә Фаухетдин кызы**
**“Арча 2 нче балалар бакчасы”**
**муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе**

## “Бишек җырлары- әнием моңнары” фольклор кичәсе

**Максат:** балаларны татар халкының әби-бабайлардан калган милли гореф-гадәтләре, борынгы йолалары белән таныштыру.
**Тәрбия бурычы**: балаларда милли гореф-гадәтләргә,йолаларга хөрмәт, ихтирам тәрбияләү,милли җырлы- биюле уеннар аша балаларда туган телгә карата мәхәббәт хисләре уяту.
**Белем бирү бурычы**: балаларның сүз байлыкларын арттыру. татар халык уеннарын һәм җырларын өйрәтү; әдәплеккә, бер-береңә карата игътибарлы булырга, олылырны хөрмәт итәргә өйрәтү.
**Үстерү бурычы:** балаларның хәтер һәм фикер йөртү сәләтен үстерү, сүз байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен камилләштерү.

### Кичә барышы.

Дәү әни ике оныгы белән бәлеш ясыйлар.
Дәү әни. Балакайларым, менә тиздән бәлеш тә пешеп чыгар. Сез миңа булышкач, бәлешне тиз генә әзерләп мичкә куйдык бит. Итле бәлеш татар халкының иң тәмле милли ризыкларының берсе инде ул. Гаиләбезгә шатлык, өмет һәм куанычлар өстәп, өченче оныгым дөньяга килде бит. Балакайлар, озакламый эти-әниләрегез дә кечкенә бәбиебез белән кайтып җитәрләр.
Камилә. Дәү әни, дус кызларымның да безнең кечкенә сеңлебезне бик тә күрәселәре килә. Дусларым кунакка керсәләр, әнием сүз әйтмәс микән?

Дәү әни. Балакайларым, дус кызларың да керсеннәр.    Бергәләшеп, күңелле итеп сеңлегезне каршы алырбыз. Бәбиебезгә  исем дә уйларга кирәк бит әле. Бишекне дә әзерләп куярбыз, Аллаһ боерса.   Халкыбызда бәби туу белән бәйле йолалар  бик күп  һәм алар хәзер дә саклана.
Адилә. Шул  йолалар турында безгә дә  сөйлә әле, дәү әни.
Дәү әни.    Рәхмәт яугырлары, бик рәхәтләнеп  сөйләрмен.
 Камилә. Алайса мин   дусларымны  тизрәк  кунакка   чакырыйм әле, дәү әнием. Аларга хәзер   тиз генә телефоннан хәбәр  җибәрәм дә, озакламый  килеп тә  җитәрләр.
Дәү әни. Әйдәгез,балакайлар, өстәлне көйләп алыйк. Сез  өстәлгә чәк-чәкне, коймакны һәм балны куя торыгыз, мин тиз генә самоварны куеп керәм. Тиздән  бәлеш  тә  өлгерер, Аллаһ боерса. (Дәү әни самоварны алып  чыгып китә).
Камилә. Адилә, кызлар килеп тә җитте  инде!  Каршы алыйк   кунакларны!
Адилә.    Кем бар анда?
Ишек артыннан тавыш.  Бәлеш исен сизәбез, кунакка без  киләбез.
(Кызларның кулларында күчтәнәчләр. Кызлар кереп, ярымтүгәрәк итеп басалар)
Зилә.   Исәнмесез, дусларым!
Хәерле көннәр  булсын!
Уен – көлке, җыр – моңнан
 Күңелләребез тулсын!
Ралинә.  Сабыегыз тормыш яме булып,
Ай үсәсен үссен көнендә.
Нәселегезнең гореф-гадәтләрен
Саклап барсын алгы көннәргә.
Руфина. Ай нурлары булса кичтән ,
Таң нурыдай булсын иртәсе.
Сездә булган барлык яхшылыкны,
Буыннарга аның илтәсе.
Адилә.  Исәнмесез! Хәерле көн!
Рәхим итегез түрдән!
Айсылу.     Ачуланмагыз  инде, кызлар,  шәһәрдән  рус кызы кунакка кайткан иде. Аны үзен генә  өйдә  калдырып булмый, үземнең дә бик бәбиегезне күрәсем  килде. Таныш булыгыз,  дус кызым- Катя.
Адилә.    Бигрәк яхшы булган . Бергә- бергә бик  күңелле булыр.
Дәү әни  бишек   тотып керә. Кунак кызлары килеп тә җиткән икән. Бик әйбәт булган. Хәзер бергәләшеп эшләп алырбыз да, аннары тәмләп  чәй эчәрбез. Тиздән самавыр да кайнап чыгар, бәлеш тә пешәр.
Камилә. Дәү әни, нәрсә эшлисе бар?
Дәү әни. Балакайлар, безгә бишекне әзерләп куярга кирәк. Бишек дигәннән, әзрәк сөйләп китим әле  Борынгы  бабаларыбыз яңа туган сабыйны  тирбәтү өчен бишек уйлап тапканнар.  Аларның ниндиләре генә юк! Нечкә тал чыбыгыннан үргәннәре дә, агачны уеп ясалганнары да, тактадан сырлап ясаганнары да...   Бишек – сабый өчен изге оя бит ул. Баланың күп вакытын рәхәттә, тынычлыкта үткәрә торган урыны. Дөрестән дә, сабыйның иң рәхәт, иң тыныч чагы бишектә яткан вакыты бит. Бала бишектә тирбәлә, анда изрәп йоклап китә, аңа анда рәхәт. Уянып китсә дә, ул үзен үзе тирбәтә ала, чөнки сабый селкенүгә бишек тирбәлә башлый. Күп кенә кешеләр бишек эләргә ашыкмыйлар, инде модадан чыкты дип уйлыйлар.   Ә менә  минем оныкларым  бишектә тирбәлеп үсте. Кечкенә оныгым да бишекне яратыр, Аллаһ боерса. Балакайлар,  күрәсезме, түшәмдә божраны ?  Менә шул божрага   сиртмәле  ыргак белән  бишекне эләбез дә инде. Әйдәгез, миңа булышыгыз әле. (Балалар белән  бишекне элеп куялар).
Дәү әни. Балакайлар, сезнең чыбылдык сүзен ишеткәнегез бармы?
Балалар. Юк.

Дәү әни. Чыбылдык ул – бишек өстенә каплап куела торган тукыма. Бишекне чыбылдык белән ябып куйгач, нәни бәби өчен кечкенә генә өй барлыкка килгән: һава да җылы, тирбәткәндә җил дә керми, чебен-черки дә борчымый. Әйдәгез, бишеккә чыбылдыкны да элеп куйыйк. (Бергәләшеп чыбылдыкны эләләр).

Дәү әни. Менә бишегебез әзер дә булды. Шушы бишеккә бәбине салып, бишек җыры да җырласаң, бәби рәхәтләнеп йоклап китә инде. Балакайлар, сезгә әниләрегез бишек җырлары җырлыйлармы соң?

Энҗе. Минем әнием кечкенә энемне татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның “Бишек җыры”н җырлап йоклата.

Камилә. Дәү әнием, ул җырны безгә бакчада тәрбияче апаларыбыз өйрәтте. Дусларым, дәү әнигә җырлап күрсәтик әле.

Г.Тукай “Бишек җыры”

Әлли-бәлли итәр бу
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тырышып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Йокла ,углым ,йом күзең,
Йом-йом күзең , йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Елап үтә көндезең.
Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем,
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Дәү әни. Бишек җыры җырлаганда ана сабыена үзенең изге теләкләрен тели. Бишек җырлары тыңлаган сабый тыныч холыклы булып үсә. Бала сөйләшә белмәсә дә, сүзләрне аңламаса да, җырны тыңлап изрәп йокыга киткән. Дәү әни. Балалар, ишеттегезме, бишек җырында әнисе сабыена нинди матур сүзләр белән эндәшә? Ә сезгә әниләрегез нинди ягымлы сүзләр әйтә соң? Әйдәгез, без моны белү өчен “Ягымлы сүзләр”уенын уйнап алыйк.

“Ягымлы сүзләр” уены. (Бишек җыры башлануга бер-беребезгә курчакны тапшырабыз. Көй туктагач, кемдә курчак кала, шул ягымлы сүз әйтә).

Камилә. Әйдәгез, дусларым,
Түгәрәкләргә басыйк.
«Зәңгәр чәчәк» уенын
Бергәләп уйнап алыйк!

«Зәңгәр чәчәк» уены уйнала.

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.
Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләреңә ипле булыр -
Мендәреңне сал әле.

Дәү әни. Мин оныткан да идем инде бу уенны, менә искә төшердегез бит, рәхмәт яугырлары.

Адилә. Дәү әнием, сеңлебезгә нинди исем кушарбыз икән?

Дәү әни. Халкыбызда бәби туу белән бәйле йолаларның иң беренчесе исем кушу. Исем ул кешенең язмышын билгели торган нәрсә дип каралган. Элек-электән мәгънәле эчтәлеккә ия булган исемнәр кушканнар. Мулла килеп азан әйтеп, исем куша, балага бәхет теләп, дога кыла. Исем кушуга хәзер халык бик игътибар итә. Әти-әни баласының бәхетле, озын

гомерле, игелекле булуын тели, шуңа күрә сүзлекләрдән карап, укып исем сайлыйлар. Менә сез, балакайлар, үз исемнәрегезнең нәрсә аңлатканын беләсезме? Тагын бер уен уйнап алыйк сезнең белән. Мин хәзер кулъяулыкны төйним дә берәрегезгә ыргытам. Төенләнгән кулъяулыкны кемгә ыргытам, шул үз исеменең мәгънәсен әйтә.
Камилә. Тулы, бөтен, һәрьяктан камил килгән.
Адилә. Гадел, намуслы, дөрес, тугры.
Айсылу. Ай кебек» сылу, чибәр.
Гүзәл. Бик матур.
Катя. Чистая, безупречная.
Зилә. Зилә — миһербанлы.
